• ЗӘКЯТ •
МАЛДАН ЗӘКЯТ ЧЫГАРУ
*6 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •
ПЛАСТИКА ОПЕРАЦИЯЛӘРЕ РӨХСӘТ ИТЕЛӘМЕ?
*7 бит*

• ВАКЫЙГА •
ТАТАР ӨММӘТЕНЕҢ ИСЛАМ ҮСЕШЕНДӘГЕ РОЛЕ
*9 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
АГУЛЫ САБАК
*14 бит*

*№ 2 (295)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Җөмәдәл-ахыр 1441*

*Февраль, 2020*

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Рәгаиб – раҗәб аеның фазыйләтле кичәсе




*Тулырак 4 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Тел галиме, язучы, тарихчы…



14нче февральдә, татар мәгърифәтчесе, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф Каюм Насыйриның тууына 195 ел тулды. Ул элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә дөньяга килә.

К.Насыйри гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә нигез сала.

Татар лексикологиясе буенча – русча-татарча «Лөгать китабы» сүзлеге (1892), татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге «Ләһҗәи татари» (1–2 т., 1895–96); фонетика һәм грамматика буенча «Кавагыйд китабет, ягъни тасниф вә имлә кагыйдәләрен бәян кыйлучы бер яңа фәндер» (1892), «Әнмүзәҗ. Лисаныбызның сарыф вә нәху кагыйдәләре бәянында» (1895) хезмәтләрен яза.

Кеше акылына, фәнгә, этика, тел мәсьәләләренә, фольклор, әдәбият, музыкага һәм башкаларга багышланып, 40 бүлектән торган, асылда беренче татар энциклопедиясе «Фәвакиһелҗөләса фил-әдәбият» (1884) фундаменталь хезмәте татар тарихында зур яңалык була.

К.Насыйриның фәнни хезмәтләренең күбесе татар халкы тарихын, Россия һәм гомумхалык тарихын өйрәнүгә багышлана.

Этнографиягә караган хезмәтләрендә бик күп халык сынамышлары, әкиятләр, әйтемнәр, җырлар, туй, мәет озату һәм башка гаилә йолалары тасвиры, татар халкының матди мәдәниятен тәшкил итә торган йорт-җир, кием-салым, азык-төлек, халык медицинасы турында мәгълүматлар зур урын ала.

К.Насыйри җитәкчелегендә 1871–1897 дә (1886, 1887, 1895 елларда туктатылып тора) ел саен «Казан календаре» басылып чыга. Анда, календарьларга хас мәгълүматтан тыш, күп кенә фәнни һәм әдәби материал да бирелә.

Каюм Насыйри – мәгърифәтче галим, татар фольклорының күп кенә жанрларында да эшләп, халыкның рухи байлыгын, акыл һәм күңел җәүһәрләрен барлап, бергә туплап, халыкның үзенә кайтару юлында хезмәт иткән.

■ **dumrt.ru**

# Нәзарәттә Голәмәләр шурасы утырышы үтте

14 нче февральдә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә Голәмәләр шурасының чираттагы утырышы үткәрелде. Көн тәртибендә мөһим, көнүзәк мәсьәлә буларак, Рамазан аена әзерлек мәсьәләләре каралды. Шура әгъзалары Рамазан ае өчен намаз уку һәм авыз ачу календарьларен һәм буклетларын тарату, ураза тотуга һәм тәравих намазларын укуга кагылышлы белешмәлекләрне әзерләү мәсьәләләрен карады. Шулай ук, Рамазан аеның көннең иң озын вакытларына туры килүен исәпкә алып, халыкка ураза тотуның фазыйләтләрен аңлатып «Хозур» телевидениесе аша тапшырулар әзерләү кирәклеге ассызыкланды. Моннан тыш, гыйбадәт кылу һәм хәләл мәсьәләләренә караган сораулар буенча Голәмәләр шурасының эшче төркемен булдыру тәкъдиме ясалды. Шураның җаваплы сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев «BestWay» компаниясенең мөселманнарны алдап, Диния нәзарәте исеменнән чыгып төрле ялган һәм шикле ислам финанс хезмәтләрен тәкъдим итүләре хакында бәян итте. Голамәләр дин кардәшләрне игътибарлы булырга чакырды.

■ **dumrt.ru**



# Аксакаллар шурасы рәисе яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары белән очрашты




17 нче февральдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Тимур Сөләйманов белән күреште. Очрашу министрлыкта узды һәм бер сәгатьтән артык дәвам итте. Беренче чиратта Айрат хәзрәт Тимур Җәүдәт улына җылы каршылавы, бар көчен, белемен, тырышлыгын куеп, яшьләр сәясәте өлкәсендә ару-талуны белми эшләве өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде. Алга таба Айрат хәзрәт Әюпов Тимур Сөләймановны Татарстан мөфтиятенең эшчәнлеге белән таныштырды, аеруча Аксакаллар шурасы, социаль бүлек тарафыннан алып барылган проектлар турында сөйләп узды.

– Татарстанның һәрбер районында мөхтәсибәтләр бар, аларда яшьләр бүлекләре, Аксакаллар шурасы эшли. Шуны күздә тотып, Яшьләр эшләре министрлыгы белән килешү төзергә тәкъдим итәм, шушы килешү нигезендә барлык эшләрне дә бергә эшләү турында вәгъдә бирәм. Без яшьләргә мирас калдырырга тиешбез. Әлбәттә, мәчетләребезгә намаз укучы яшьләребез килә. Тик безгә дини булмаган яшьләр белән эшләргә, аларны татар милләте, динебез, мирасыбыз белән кызыксындырырга кирәк. Килешү нигезендә, министрлык белән әлеге юнәлешләрдә эш алып барырга ниятлибез.

Тимур Сөләйманов Айрат хәзрәтнең идеяләрен хуплады һәм якын арада килешүне имзаларга сүз бирде.

■ **dumrt.ru**

# Суфичылык - рухи яктан камилләшү юлы



Безнең төбәктәге Ислам дине тарихы турыдан-туры тәсаввуф (суфыйчылык) белән бәйләнгән. Мөселманнар бер Аллаһыга булган ихлас иманнарын күп очракта Пәйгамбәребезнең (саллəллаһу галәйһи вә сәллам) рухи дәвамчылары аша кабул иткән һәм саклап калган.

Тәсаввуфның Идел буенда бик күптәннән үк данлы тарихы, үзенчәлекләре бар. Идел буе Болгар дәүләтендә суфыйчылыкның төгәл кайчан барлыкка килүе турында әйтү кыен, ләкин, XII гасырда болгарлар арасында Ясәвия тарикате (ул Хуҗа Әхмәд Ясәви тарафыннан нигезләнә) тарала башлый. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы татар тарихчысы Хөсәмеддин бине Шәрәфеддин Болгариның «Таварихе Болгария» («Болгар тарихы») китабында бу тарикать тарафдарларының исемнәре китерелә. Суфилар татарлар арасында Ислам дине таратуга шактый зур өлеш керткәннәр.

Урта гасырлар татар әдәбияты тәсаввуф белән бик тыгыз бәйләнгән. Күпчелек татар шагыйрьләре суфилар булган. Алар үз әсәрләрендә рухи һәм әхлакый камиллеккә ирешү турында язып калдырган. Тәсаввуф – ислам фәннәренең берсе, ул күңелне пакьләргә һәм рухи яктан камилләшергә чакыра. Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларындагы татар-төрки язучылары, шагыйрьләре әсәрләрендә суфыйчылык образларын, принципларын очрата алабыз. Казан ханлыгы галимнәре Ясәвия тАрикате тарафдарлары булган. Алар арасында иң зур ихтирамга лаеклыларның берсе – Кол Шәриф (туган елы билгесез). Тарихи чыганаклар буенча, ул 1552 елны руслар Казанны яулап алган вакытта һәлак булган. Кол Шәриф шигъриятендә Ясәвия традицияләре ап-ачык күренә. Мәсәлән, аның күпсанлы шигырьләренең берсе Сөләйман Бакырганиның улы Хөбби Хуҗага багышланган. Сөләйман Бакыргани (1111-1186) Әхмәд Ясәвинең (XI йөзнең ахыры –1166 ) шәкерте булган.

XVI гасыр урталарыннан, Казан ханлыгы яулап алынганнан башлап, мәчетләр, мәдрәсәләр җимерелә, мөселманнар үз ватаннарында дини белем алу мөмкинлегеннән мәхрүм кала, ислам гыйлеме алу өчен, алар Урта Азиягә, Бохарага йөрергә мәҗбүр була. Ул вакытта Урта Азиядә суфыйчылык киң таралган була, анда китүчеләрнең күбесе тәсаввуф юлына баса. Кайберләренә рухи тәрбия бирергә рөхсәт (иҗәзәт) бирәләр. Татарларда XVII-XVIII гасырларда ислам күп очракта суфыйчылык идеяләре белән тиңләштерелә. Суфыйчылык, өстенлек итүче дини институт буларак, татарлар тормышының бар якларына да йогынты ясаган: гаилә мөнәсәбәтләреннән башлап, социаль-сәяси карашларга кадәр. XVII-XVIII гасырларда татарлар арасында, башка традицияләрне (мәсәлән, Ясәвия традицияләрен) алыштырып, Нәкышбәндия тарикате (ул Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1331-1389) тарафыннан нигезләнә) киң тарала. XVIII – XIX гасырларда күп кенә татар дин галимнәренең рухи остазлары Нәкышбәндия тарикатеннән булган. Мәсәлән, шагыйрь, дин гыйлеме белгече Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834) – шәех Фәезхан Әл-Кабулидан; мәгърифәтче, ислам галиме Габеннасыйр Курсави (1776-1812) – шәех Ниязкол Әл-Төрекмәнидән; олуг галимебез, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) – шәех Гобәйдулла бине Ниязкулидан, Габделкадыйр Әл-Фаруки Әл-Һиндидән, шәех Мәзһәрдән рухи тәрбия һәм белем алганнар. Алар барысы да шәригать нигезләрен өйрәнгәч кенә, тәсаввуф юлына басканнар. Үз хезмәтләрендә алар, мөселманның беренче бурычы – хак иманга ия булу, икенче бурычы – фикһ мәсьәләләрен өйрәнү, бары тик аннан соң гына – тәсаввуф юлына басу, - дип язганнар.

> Күп кенә хәзерге мөселман яшьләре үз рухи традицияләрен, халкыбыз тарихын белмиләр.

XX гасырның 17 елларыннан башлап, татар мәдрәсәләре Нәкышбәндия тарикатендә булган дин әһелләре тарафыннан контрольдә тотыла. Ул вакытларда имам сайланганда халык лаеклы остазы булган намзәдкә (кандидатка) өстенлек биргән. Ягъни, суфи булмый торып, җәмгыятьтә абруй казанып булмаган. Ул чорларда суфыйчылык татар халкының дини һәм милли үзенчәлекләрен саклап калырга хезмәт иткән.

XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап, Россиядә суфыйчылык яңадан торгызыла башлады. Татарстанда традицион тарикать тарафдарларының саны арта бара. Традицион тарикатьләр Исламның гүзәллеген һәм югары әхлагын чагылдыралар, динебезнең әдәп принципләры таралыш алуга ярдәм итәләр. Тарикатьләр – экстремистик ислам агымнарына альтернатива.

Телəсә кайсы кешенең күңеленә ачкыч табарга була. Бу аны үгетләүче кешенең күңел пакьлегенә, аның халәтенә бәйле. Тарикать остазларының ихлас кичерешләре, белемнәре Ислам диненең чын матурлыгын җиткерергә, Аллаһыга, Аның Пәйгамбәренә (саллəллаһу галәйһи вә сәллам) булган чын сөюне тоярга ярдәм итә.

Шуның өчен, безнең халыкның рухи традицияләрен торгызу, аларны яшьләргә җиткерү – аеруча мөһим. Моның өчен бар мөмкинлекләр дә бар. Тәсаввуфның асылы - күңелләребезне сафландыру. XVII-XIX гасырларда халкыбыз тормышы җиңел булмаган, ә кайвакыт гаять дәрәҗәдә авыр булган. Суфыйчылык сабырлык, Аллаһы Тәгаләгә сыгыну, Аның рәхим-шәфкатенә өмет баглау кебек төшенчәләрне халык өчен бик әһәмиятле иткән. Алар безгә XVII гасырда яшәгән Мәүлә Колый («Хикмәтләр»), XVII гасыр ахыры XVIII башында яшәп иҗат иткән Аллаһияр Суфи «Собател гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») китабы кебек суфи шагыйрьләр аша килеп ирешкәннәр.

Намаз уку, ураза тоту, Аллаһыга гыйбадәт кылуның башка төрләре безне яхшы якка таба үзгәртәләр, рухи яктан баеталар. Тәсаввуф рухи-әхлакый яктан камилләшүнең өстәмә ысулларын тәкъдим итә, аларга өйрәтә. Традицион тарикатьләр безне тыйнаклыкка, сабырлыкка, игелекле гыйлемнәр алуга омтылырга өйрәтә.

Шәех Вәгыйзь Кәшифи (куддисаллаһу сирруһу) әйткән: «Суфилар өч нәрсәдә башкаларга үрнәк булып торалар: киракксез, урынсыз сүзләрдән тыелуда, файдасыз эшләргә алынмауда һәм Ахирәттә файдасы тиячәк эшләрне эшләүдә».

> Мөселман – югары әхлаклы кеше дигән сүз.

Тарикать остазларыбыз бер вакытта да зәһедкә, бикләнеп ятуга өндәмәгәннәр, киресенчә, җәмгыятьтә яшәргә, гаилә корырга, гомуми проблемалар белән яшәргә, дөньяны яхшы якка үзгәртергә тырышырга, ләкин, шул ук вакытта һәрвакыт Аллаһы белән булырга чакырганнар. Шәех Баһаветдин Нәкышбәнди әйткән: «Күңел – Сөеклегә (Аллаһыга), ә куллар – эшкә», – дигән. Аллаһы Тәгалә белән япа-ялгыз булуга караганда, Аллаһы белән һәрдаим җәмгыятьтә булу яхшырак.

■ **Нияз хәзрәт Сабиров,**
**ТҖ МДН Голәмәләр шурасының**
**әгъзасы**

# Рәгаиб кичәсе

Мактау вә дан галәмнәрнең Раббысы, Рахмән, Рахим вә Кыямәт көненең Хуҗасы булган Аллаһыга хастыр. Тик Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, тик Синнән генә ярдәм көтәбез. Безне тугры юлга, Үзең нигъмәтләндергән кешеләрнең юлына күндер. Газапка дучар булганнар, адашканнарның юлыннан читләт.



> Бу айның беренче җомгасы – Рәгаиб кичәсе көне – җомга алдындагы кичтән башлана, ягъни пәнҗешәмбегә туры килә.

Бу айның беренче җомгасы – Рәгаиб кичәсе көне – җомга алдындагы кичтән башлана, ягъни пәнҗешәмбегә туры килә. Ислам динендә кичә көндездән алда бара, чөнки кояш баеганнан соң икенче көн башлана. Нинди көн соң ул Рәгаиб кичәсе? Бу – Пәйгамбәребезнең әтисе Габдулла белән әнисе Вәһаб кызы Әминәнең никахлашкан көннәре.

Ни өчен без Рәгаиб кичәсен билгеләп үтәбез? Чөнки шушы никах нәтиҗәсендә дөньяга рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяга килгән.

Хәзрәти Габдулладан да, хәзрәти Әминәдән дә алтыннар, байлыклар калмаган. Аларның никахыннан дөньяга бер изге бала туган. Бөтен никахларның максаты, нәтиҗәсе – бала. Әгәр без үзебездән соң холык ягыннан да, әхлак ягыннан да – бөтен яктан үзебезгә караганда яхшырак балалар калдырабыз икән, димәк, безнең гомеребез заяга үтмәгән, димәк, без Аллаһы Тәгалә каршысында бурычыбызны үтәгәнбез дигән сүз. Пәйгамбәребезнең әтисе – улы туганчы, әнисе – улына алты яшь вакытта вафат булалар. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм ятим кала. Әмма хәзрәти Габдулла белән хәзрәти Әминәнең саф җаннар, изге күңелле кешеләр, харамга катышмаган яхшы кешеләр булганы өчен, Аллаһы Тәгалә изге бала биреп дөньяны сөендерә.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең әйткән сүзе бар: «Аллаһыны танымаган, харам белән хәләлне аермаган, изге гамәлләр кылмаган кешегә Аллаһының беренче җәзасы – дөньяда юлдан язган бала булыр. Ата-ананың төрле юллар белән тырышып-тырмашып җыйган байлыгын туздырыр өчен, картлык көнендә бөтен тынычлыгын алыр өчен шушы бер бала җитә, шушыннан артык бернәрсә дә кирәк түгел».

«Хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы – ир хакы, ирләр һәм хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы – ана хакыдыр» (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Бу хәдистә хатыннар өстендә булган ирләр хакы һәм ирләр һәм хатыннар өстендәге аналар хакы бәян ителгән булса да, ирләр өстендә хатыннарның да, аналар һәм аталар өстендә балаларның да хаклары бар һәм алар күп. Аларны яхшылап белү һәм шул белгәннәр белән гамәл кылу, белер өчен уку, сорап булса да өйрәнү тиешле. Милләтләрнең иҗтимагый камилләшүләре гаиләләрдәге шәхесләр арасындагы бердәмлек һәм өлфәт-мәхәббәткә бәйле булганлыктан, өйләнүнең табигый булуы һәм аннан соң шәхесләрнең үзара хакларының тиешле дәрәҗәдә үтәлүе лязем. Гадәттә, өйләнешү ир белән хатынның яшь һәм әхлакта, гыйлем һәм табигать кебек эшләрдә берберсенә туры килүләреннән гыйбарәт. Бу нәрсәләргә игътибар бирелмәгән никахларда ир хакы да, хатын хакы да үтәлми, бәлки күп вакытта хәерсез эшләргә сәбәп була. Әгәр без, Аллаһыны танымыйча, теләсә нәрсә эшләп йөрсәк, безгә Аллаһы Тәгалә игелексез бала бирүе бар. Безгә җәза бу һәм инде, киресенчә, харамга катышмыйча, изге гамәлләр кылып, тормышның авырлыкларына сабыр итеп, үзебезне кешечә тотсак, хайван дәрәҗәсенә төшмәсәк, безгә Аллаһы Тәгалә бүләк итеп изге, миһербанлы бала бирер.

> Раҗәб аенда ураза тоту бик саваплы гамәл. Кемнең көче, ихтыяры җитә – уразага керик.

Рәгаиб кичәсе башлангач, моны без: гаилә кичәсе, гаилә көне, дибез. Раҗәб аенда ураза тоту бик саваплы гамәл. Кемнең көче, ихтыяры җитә – уразага керик. Кояш баешка хәләл ризыклар белән табыннар әзерлик. Гаилә белән шундый табыннар янында бергәләшеп сөйләшеп утырыйк. Бер-беребезгә изге теләкләр телик, бүләкләр бирешик. Кемнәрдер әти-әни булырга җыена – шушы көнне садакалар биреп, изге гамәлләр кылып, үзләренә Аллаһы Тәгаләдән изге бала сорасыннар. Баласы булганнар үзләренең балаларына тәүфыйкъ-һидаять бирүне үтенсеннәр. Ир белән хатын никахларына тугрылык сорасыннар. Ир – хатынына, хатын иренә бүләк биреп, матур-күркәм сүзләр әйтеп, шушы көнне үзләренең никахларын ныгытсыннар.

Кияүгә чыкмаган, өйләнмәгән егеткызлар бу кичәдә Аллаһы Тәгаләдән бер-берсенә тиң ярларны сорасыннар. Карт-карчыклар бу кичәдә Аллаһы Тәгаләдән тигез гомер, бергә-бергә, таза-сау, тигез яшәүләрен үтенсеннәр. Раҗәб аенда Аллаһының рәхмәте яңгыр шикелле явар, диелгән. Менә шушы рәхмәт аенда, бигрәк тә җомга көнендә, үзебезнең мөселман икәнебезне тоеп, бәйрәмне зурлап, Аллаһы Тәгаләгә муафыйк эшләп кылып, хәерле теләкләрне телик. Үзебез өчен дә, балаларыбыз һәм киләчәк буын өчен дә догада булыйк. Гаилә нигез яши, никахның ныклыгы нинди – киләчәгебез шундый. Никахларыбыз төзек булмаса, аны игътибарга алмыйча яшәсәк, без хайван шикелле гомер иткән булабыз һәм үзебездән соң да юньле буын калдыра алмабыз. Балаларыбызның үзебездән начар булуы ихтимал. Әмма начар холыклы әти-әнинең дә баласы, әти-әнисенең хаталарыннан азат булып, яхшы бала булып үсәргә мөмкин. Әти-әнинең бурычы – тәрбияле бала үстерү.

Аллаһы Тәгалә каршысында никах иң күркәм, иң саваплы, иң кирәкле гамәл. Бу уңайдан, бер нәрсәне әйтеп китәсе килә: никахны кайчан укырга ярый, ә кайчан ярамый?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Сафәр аенда начар билгеләр юк, әйберләрдә шомланулар юк». Бернинди ырым да булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә каршысында никах күркәм эш булгач, һич тә аптырап тормаска кирәк. Яхшы эшне эшләр өчен без берәр вакытны сайлыйбызмы? Юк. Изге эш эшләргә ярамаган көн бармы? Юк. Шуңа күрә никах укырга ярамаган көн дә, сәгать тә юк. Бөтенесе урынсыз шомлану, урынсыз ырым. 3-4 елга бер тапкыр гает белән җомга көне бергә туры килә. Менә шушы вакытта гает вакыты чыкканнан соң, җомга укыганчыга кадәр никах укымый торырга кирәк, дигән фикер бар. Бу, җәмәгать, вакыт тыгыз булудан гына, һич тә дөрес фикер түгел. Никах бу вакытта укыла. Тагын бер нәрсә бар: ураза аенда никах укылмыйча тора. Бу – яшьләрнең уразасына авырлык килмәсен өчен. Җир йөзендәге миллиардлаган мөселманнар ураза тотып, намаз укып яши. Алар никахланганнан соң да ураз тотарга тиешләр. Яшьләрнең уразаларына авырлык килмәсен дип кенә, Рамазан аенда никах укылмыйча тора. Әмма бу айда, мәсәлән, ураза вакытында никах укыла, ә авыз ачылганнан соң никах мәҗлесе ясалса. Рамазанда никах укырга ярамый дигән фикер дөрес түгел.

Әмма иң борчыганы, иң әрнеткәне – никах мәҗлесен харам туйга – хәмер туена әйләндерү. Бер генә гаилә нигезен дә аракы ныгытканы юк. Бер генә дәүләтне дә аракы ныгытканы юк. Аракы эчеп, теләк теләп, берәүнең дә уңганы юк. Аракы – бозыклыкларның анасы, һәм без, шушы никах көнне – гаилә кавышкан көнне – бозыклыкның иң начарын эшләп, сез әйбәт торыгыз, дип теләк телибез. Аллаһы сакласын.

Никахта кыз бала да, ир бала да: риза булып бардым, риза булып алдым дигәч, Аллаһы Тәгалә каршысында да, бәндәләр каршысында да вәгъдә биргән була. Хатын-кыз иремне ир итеп санармын дип, ә ир кеше хатынымны хатын итеп тотармын дип вәгъдә бирә. Һәм әти-әнине дә догасын алырлык итеп, алар риза булырлык итеп тәрбияләп озатырмын дип әйтә. Балаларымны да шәригатькә муафыйк итеп, Аллаһы Тәгалә кушканча тәрбияләп үстерермен дип әйтә. Никах менә шундый була.

Балаларыбызны никахка җитди итеп әзерләргә, үзебезгә дә никахыбызга хилафлык китермичә, аңа тугры булып яшәргә тиешбез.

***Ирек хәзрәт Җәмалов***

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән:

Муса галәйһиссәламнең апасы шулай дип әйткәч, сүзләренең дөреслегеннән шикләнеп, аны сарай эченә алып кереп:

– Син әйткән гаилә балага карата яхшы мөнәсәбәттә булачагын син каян беләсең? – дип сорыйлар.

Муса галәйһиссәламнең апасы үзен фаш иттермәскә тырышып:

– Ул патша гаиләсендә сөт анасы булырга тели һәм моннан бернинди дә файда эзләми, – дип җавап бирә.

Шуннан соң ул сөйләгән хатынны китерергә кешеләр җибәрәләр. Муса галәйһиссәламнең әнисе сарайга шундук килеп җитә. Әнисе баласын кулына алу белән үк, ул аның күкрәгенә сыенып имә башлый, елаудан туктый. Сарай әһелләре, иң беренче чиратта, Асия бинте Мөзаһим моңа бик шатланалар, Муса галәйһиссәламнең анасына күп бүләкләр бирәләр.

Ләкин фиргавенне тагын шикшөбһәләр баса. Бераз уйлап торгач ул:

– Син бу балага кем буласың? Ул башка имезүчеләрдән баш тартты, ә сине кабул итте, – дип әйтә.

Муса галәйһиссәламнең әнисе аңа:

– Минем тәнем хуш исле һәм сөтем дә тәмле. Минем сөтне ошатмаган бер генә бала да юк, – дип җавап бирә.

Бу сүзләр фиргавенне ышандыра һәм туендырыр өчен Муса галәйһиссәламне әнисенә бирәләр. Моннан тыш алар аны яшәү чыганагы белән тәэмин итәләр һәм күп бүләкләр тапшыралар. Муса галәйһиссәламнең әнисе моннан бик канәгать була һәм баласын алып өенә кайта.

Аллаһы Тәгалә аны куркудан азат итә һәм аңа башкалар арасында хөрмәт, югары дәрәҗә, муллык ирештерә. Күрәсез ки, һәр авырлыктан соң Аллаһы Тәгалә аннан чыгу юлын күрсәтә, җиңеллек бирә.

**«Күңеле тыныч булсын һәм (аерылу сәбәпле) сагышланмасын, янә, һичшиксез, Аллаһының вәгъдәсе хак булганын белсен өчен, Без аны әнисенә кайтардык, ләкин аларның күбесе (Аллаһының сүзе, һичшиксез, үтәләчәген) белмиләр».**

«Касас / Хикәя», 28:13

Хәдисләрнең берсендә Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләре тапшырыла: «Мусаның анасы изге ниятләр белән, Аллаһы Тәгаләдән генә савап-лар алырга өмет итеп ниндидер гамәл кылучы кешеләргә үрнәк булып тора. Ул үз улын туендырды, аның өчен саваплы да булды».

## Ут һәм алтын белән сынау

Риваятьләрнең берсендә фиргавен, Муса галәйһиссәламнән бик нык курыкса да, аны яратып кочагына ала, дип тапшыралар. Ул аның белән бераз уйнарга теләгән. Фиргавеннең кочагына эләккән Муса галәйһиссәлам аны сакалыннан тотып ала да, нык кына итеп шул сакалыннан тарта. Шуның аркасында фиргавен башы белән мәрмәргә бәрелә. (Муса бик көчле була, чөнки аңа фиргавен әмере буенча үтерелгән бар балаларның көче бирелгән була). Фиргавен чак кына башын ярмый кала. Шуннан соң ул зур куркуга төшә һәм бик нык ачуы чыгып: «Бу бала мине үтерәчәк. Бу – күрәзәчеләр алдан әйтүенчә, минем хакимлеккә чик куячак бала», – дип кычкыра. Аннары ул бу баланы үтертү өчен җәлладны чакырырга куша. Ләкин Асия бинте Мөзаһим аңа каршы:

– Ул бит кечкенә бала гына. Аның бернинди дә начар нияте һәм максатлары була алмый, – ди.

Ләкин фиргавен курку һәм гаҗәпләнүеннән, бу бала бәлки үзенең үлеменә сәбәпче булыр дип уйлап, бер ноктага карап торуын дәвам итә. Шуңа да ул Муса галәйһиссәламне үтерергә карар кыла. Әмма бернигә дә карамый Асия бинте Мөзаһим баланы яклавын дәвам итә һәм соңгы өмете белән:

– Әгәр дә син шулай уйлыйсың икән, без бу баланы сынап карыйк. Бу бала син уйлаганча акыллы, үзенең ни эшләгән аңлап эшли икән, син ул чакта аны үтерерсең. Әгәр дә алай булмаса, син аны үтерми калдырып миңа бирерсең, – дип әйтә.

Шуннан баланы сынап карар өчен фиргавен ут ягарга һәм алтын китерергә куша. Аннары, аларның кайсына үрелер дип карар өчен, ут белән алтынны бала алдына куялар. Гади бала утның якты януына кызыгып, кулын пешерәсен аңламыйча утка үрелергә тиеш була. Әгәр дә Муса галәйһиссәлам кулын утка түгел, ә алтынга таба сузса, бу аның бик тә акыллы, барысын да аңлый торган гайре акыллы бала булуын һәм фиргавенне башы белән мәрмәргә махсус бәрүен аңлатачак. Шул сәбәпле бу баланың киләчәктә фиргавенне һәлак итәчәк һәм аның хакимлегенә чик куячак бала икәнлеге дә билгеле булачак иде.

Сез: «Муса галәйһиссәлам кайсына үрелгән соң?», – дип сорарсыз.

Әлбәттә ул, бик тә акыллы бала булса да, ул утка үрелгән. Әмма шул вакытта Җәбраил галәйһиссәлам килеп Муса галәйһиссәламнең кулын утка таба борган. Ул гына да түгел, ул утлы бер күмер кисәге алып авызына сузган, хәтта телен дә көйдереп өлгергән. Шуның аркасында ул сакау сөйләшә торган булып калган.

Ягъни, утка сузылып ул кулын һәм телен пешерсә дә, үзенең гомерен саклап калган, соңыннан сакаулыгыннан да котылган. Аллаһы Тәгалә билгеләгән вакыт җиткәч, Ул Муса галәйһиссәламгә:

«Фиргавенгә бар, ул рөхсәт ителгәннәрнең чиген үтеп китте», – дип әйткән.

Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән бу әмерне алгач:

**«И Раббым! Минем күкрәгемне киң кыл! Эшемне миңа җиңел ит. Телемдәге төенне чиш»,** – дигән.

«Та һа», 20:25-28

Аның бу үтенече кабул ителә, ул тотлыкмый башлый.


Бик күп дәгъватчы һәм вәгазьчеләр дингә чакыруларын шушы дога белән башлый. Раббыбыз ярдәменнән башка без фикерләребезне һәм сүзләрне җыеп әйтә алыр идекмени? Ул безнең тел һәм зиһен ачкычларыбызны ачмаса, без көненә намаз вакытында 40 тапкыр укыла торган «Фәтихә» сүрәсен укыганда да хаталар җибәрер идек.

Фиргавен үзе нишли соң? Аның тәкәбберлеге, мин-минлеге чамасыз була, ул рөхсәт ителгәннәрнең бар чикләрен дә үтеп чыга һәм үзен Раббыга исәпли башлый. Ул башта «Мин сезнең Раббыгызмын», – ди, ә аннары:

**«Сезнең бөек Раббыгыз – мин!»** – дип әйтә.

«Нәзигат / Суыргучы», 79:24

Каян чыгып үзен Аллаһыга тиңли соң ул? Чынлыкта Яратучы аңа күп хакимлек, байлык һәм озын гомер насыйп итә. Ул хәтта авыруны да белми. Нәтиҗәдә, ул үзен гади кешеләрдән аерыла, дип тоя. Моңа өстәп фиргавен янында булган вәзир-киңәшчеләр һәм хезмәтчеләр дә аңа куштанланып, «Син – гадәттән тыш кеше», дип ышандыра. Хакыйкатьтә, кешене мохит һәм яндагы иптәшләре һәлак итә ала. Киңәшче Хаман үзенең хөкемдарын һәлак иткән шикелле.



## Фиргавенгә кызыгырлык тәкъдим ясыйлар

Хаман исемле кеше фиргавеннең баш вәзире һәм төп киңәшчесе була. Фиргавеннең үзен Раббы дип игълан итүенең төп сәбәпчесе нәкъ менә ул була да инде.

Риваятьләрнең берсендә фиргавеннең бервакыт үзен Раббы дип раслаудан баш тартырга ниятләве турында тапшырыла. Ул иманга килү турында уйлана башлый, чөнки Муса галәйһиссәлам аңа шундый тәкъдим ясый:

– Әгәр дә син иманга килсәң, Аллаһы Тәгалә сиңа яшьлегеңне һәм элекке көчеңне кире кайтарыр. Ахирәттә дә син җәннәт әһеле булырсың, – дип әйтә.

Әлбәттә мондый тәкъдим фиргавенне бик тә кызыктыра. Һәм ул:

– Туктап тор, миңа бу турыда яхшылап уйларга кирәк, – дип әйтә.

Ул баш вәзирен чакырып ала һәм аның белән киңәшләшә. Ләкин Хаман моңа катгый рәвештә каршы чыга, ул фиргавенгә:

– Син үзеңнең ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы? Моңа кадәр син кешеләргә «Мин сезнең Раббыгыз», – дип әйттең, ә хәзер инде икенче бер Раббының колы булырга телисеңме? Сиңа нәрсә вәгъдә итүләре мөһим түгел, Раббылыкка дәгъва итүдән баш тартсаң, кешеләр сине хөрмәт итми башлаячаклар һәм син җәмгыятьтә тоткан югары урыныңны югалтачаксың.

Шундый җавап ишеткәч, фиргавен кире чигенә һәм тау башыннан ычкынган зур таш кебек, аска, тәмугка таба тәгәрәвен дәвам итә.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Малдан зәкят чыгару

***Зәкят, Исламның өченче баганасы буларак, милек гыйбадәте санала. Зәкят милекне һәм җанны чистартуга, мөселманнар арасында гаделлекне саклау, байлар белән ярлыларны бердәй күрүгә юнәлдерелгән булганлыктан, җәмгыятьтә бик мөһим урын тота.***



Зәкят Коръәннең якынча 30 аятендә намаз белән бергә искә алына, бу исә зәкятнең никадәр дәрәҗәдә әһәмиятле булуын күрсәтә. «Гыйлем эстәү – һәр мөселманның бурычы» дигән хәдис тә гыйлем алырга өнди. Мөселман өчен иң мөһим гыйлемнәр фарыз гамәлләр белән бәйле, шунлыктан, галимнәребез зәкят һәм аны түләүгә кагылышлы гыйлемнәрне һәр мөселманга өйрәнүне тиешле саный.

«Зәкят» – лексик мәгънәсе ягыннан «чистарыну» һәм «үсү» дигән сүз. Шәригатьтә – нисап күләмендә милке булган кешенең хәләл юл белән табылган малыннан тиешле кешегә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бирелә торган өлеш (нисап күләменә җитеп яисә артып киткән малдан кырыктан бер өлеше, ягъни 2,5%) дигән сүз. Ислам динендә, тән һәм милек белән бәйле башка гыйбадәтләр дә булган төсле, кешегә, яшәү дәрәҗәсен исәпкә алып, үзе күтәрә алырдай зәкят бурычы да йөкләнгән.

### Зәкят түләүнең шартлары:

1. малның нисап күләменә җитүе;
2. нисап күләме малның әҗәтләрдән, тормыштагы азык-төлек, кием кебек кирәкле ихтыяҗларга булган чыгымнардан артып калган өлешеннән саналу;
3. малның чынлыкта артуы яисә арту мөмкинлеге булуы;
4. ай календаре буенча бер ел узгач, нисапка ия булу;
5. ай календаре буенча ел дәвамында малның бөтенләй юкка чыкмавы.

### Нәрсә ул нисап?

Нисап – ул шәригатьтә кешенең бай булганлыгының күрсәткече. Нисап күләме алтын белән 20 мыскалга (85 гр.), хайваннар белән булса, 5 дөягә, 30 сыер яисә 40 сарыкка тигез. Зәкятнең кемгә бирелергә тиешлеге Коръәндә («Тәүбә» сүрәсенең 60 нчы аяте), ә күләме хәдисләрдә (Сахих Бохари, «Зәкят», 32, 36, 38, 43) ачык аңлатылган. Шуларга таянып, нисапка җиткән малы булган кеше әҗәтләрен-нән һәм асыл ихтыяҗларыннан калган милкеннән зәкятен чыгарырга тиеш.

### Зәкят кем өчен фарыз? Зәкятнең дөрес булуының шартлары нинди?

Зәкят гыйбадәтенә бәйле шартлар икегә бүлеп карала: зәкятнең кемгә фарыз икәнлеген күрсәтүче шартлар һәм зәкятнең дөреслегенә кагылышлы шартлар.

Зәкятнең фарызлыгына шартлар: мөселман булу, акыллы булу, балигълыкка ирешү, азат булу, әҗәтләреннән һәм асыл ихтыяҗларыннан кала нисап күләмендә арткан яисә арту мөмкинлеге булган, ягъни керем китерә алырлык малы булу.

Болардан тыш, зәкят түләнергә тиешле мал ай календаре буенча бер ел эчендә бөтенләй юкка чыкмаска тиеш. Малның ел әйләнәсе артуы яисә кимүләре исәпкә алынмый. Зәкят вакытыннан алда да түләнергә мөмкин.

Зәкятнең дөреслегенә килгәндә, иң беренче чиратта ниятkә игътибар итәргә кирәк. Зәкят нияттән башка дөрес булмый, чөнки зәкят бирү гыйбадәт булып санала. Моннан тыш, зәкятнең «тәмлик» дигән шарты бар, ягъни малны башка кешенең милегенә тапшыру процессы. Башка шартларын үтәмичә, ризык әзерләп, берәр мохтаҗның ашавына мөмкинлек кенә бирү зәкяттән китмәячәк.

### Балигълыкка ирешмәгән балаларның милкеннән зәкят түләү тиешме?

Зәкят түләү акыллы һәм дин буенча балигълыкка ирешкән кешегә тиешле. Хәнәфи мәзһәбе буенча, балигълыкка ирешмәгән балаларның, байлыклары булуга да карамастан, зәкят түләү бурычы юк. Әмма әгәр балигълыкка ирешмәгән баланың җиреннән уңыш җыела икән, бу уңыштан гошер садакасы бирелергә тиеш.

Исламда зәкят мәсьәләсендә милекнең шәхсилеге нигез булып тора. Шунлыктан, әгәр кешенең нисап күләмендә милке бар икән, ул, әтисе белән яшәсә дә, зәкят түләргә тиеш.

### Сатарга ниятләгән милектән зәкят ничек түләнә?

Мал сатуга ниятләгән милек булып саналсын өчен, ике шартның берсе үтәлергә тиеш:

1. киләчәктә сату нияте белән алынган булу;
2. сату нияте белән җитештерелгән булу.

Әгәр кеше милкен сату ниятеннән кире кайтса, бу мал сатуга ниятләнгән милек категориясеннән чыга. Зәкят түләгәндә, сатарга җыелган малның базар бәясе күздә тотылырга тиеш. Аның беренчел бәясе һәм киләчәктә артачагы исәпкә алынмый.

### Зиннәтле бизәнү әйберләреннән зәкят түләнәме?

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикеренчә, башка шартлары үтәлгәндә, алтын яки көмештән эшләнгән бизәнү әйберләреннән зәкят түләнә. Алар куланылыштамы, юкмы – аерма юк. Имам Әбү Хәнифә (рахимәһуллаһ) әйткән: «Кемдә алтыннан яки көмештән бизәнү әйберләре булса, аны тагып йөрү өчен кулланса да, кулланмаса да, ул зәкят түләргә тиеш» (Әл-хуҗҗә галә әһлил-Мәдинә, 1/448). Алтын белән 85 грамм, көмеш белән 600 граммга җитеп, бер ел узгач та нисап сакланса, бизәнү әйберләреннән зәкят түләү тиешле. Алтын белән көмештән кала башка кыйммәтле ташлардан яисә кыйммәтле металлдан эшләнгән әйберләрдән зәкят түләнми.

### Акцияләрдән зәкят түләнәме?

Нинди дә булса оешманың акцияләрен сатып алган кеше әлеге оешма карамагында булган биналарның, җиһазларның, үзендә булган акцияләренә бәрабәр рәвештә, уртак хуҗасына әверелә. Бу очракта акционер оешманың керем һәм чыгымнарын да уртак бүлә. Керем алган очракта, акционерга тиешле дивидент өлеше һәм аның башка милке нисапка җитә икән, бу кеше алардан зәкят түләргә тиеш.

Әгәр акцияләр дивидент алу өчен түгел, ә алга таба сату өчен алынган икән, алар сату өчен булган милек категориясенә керәләр. Аларның бәясе һәм калган башка милек бәясе нисапка җитсә, бу милекнең базар бәясеннән чыгып, зәкяте түләнә.

### Зәкят түләнергә тиешле милек бәясеннән нинди әҗәтләр чигерелә ала? (Аллаһы Тәгалә һәм кол хакы)

Зәкят түләргә тиешле кеше милкеннән билгеле бер физик һәм юридик затларга бәйле булган әҗәтләрен чигерергә тиеш. Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең киң таралган фикере буенча, әҗәтне түләү срогы җитсә дә, җитмәсә дә, аңа карата булган хөкем үзгәрми. Озак еллар буенча түләнеп килә торган кредит, ипотека, торак кооперативларына булган взнослар тулысы белән зәкят суммасыннан чигерелә.

### Әҗәтле кешенең әҗәте зәкяттән китә аламы?

Акча яисә милекнең ярлы (мохтаҗ) кешенең шәхси милкенә күчүе зәкят дөреслегенең шарты булып тора. Бу очракта милекне икенче кешегә тапшыру мәҗбүри. Азык әзерләп кенә мохтаҗга ашау мөмкинлеге бирү милек тапшыруга керми. Әмма әзерләнгән ризык зәкят нияте белән мохтаҗларга тапшырылса, зәкят дөрес була. Әгәр кеше әҗәткә акча биреп торып, алардан зәкят түләргә уйламаган булса, әмма соңрак зәкят түләү фикеренә килсә, бу әҗәт акчасы зәкяттән китми, чөнки акча зәкят нияте белән бирелмәде. Бу мәсьәләдә дүрт мәзһәб галимнәре дә уртак фикердә.

### Хәләл юл белән табылмаган малдан зәкят түләнәме?

Әгәр хәләл юл белән табылмаган акчаның хуҗасы билгеле булса, бу акча хуҗасына кайтарылырга тиеш. Әгәр билгеле булмаса, яисә ярлыларга өләшеп, яисә хәйрия фондларына биреп, бернинди савап өмет итмичә, бу акчалардан арыну тиешле. Димәк, хәләл юл белән кермәгән акчадан зәкят түләнми, чөнки андый акча кешенең милке булып саналмый һәм аннан тиз арада арыну кирәк.

■ **Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды**

# Ислам динендә пластика операцияләре рөхсәт ителәме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм. Минем бер иренем икенчесенә караганда зуррак. Шул сәбәпле үземне уңайсыз хис итәм һәм, миңа калса, бу минем иремә дә ошамый, гәрчә ул бу хакта миңа ачыктан-ачык әйтмәсә дә. Башка бернәрсәгә дә кагылмыйча, миңа иренемнең формасын төзәтү өчен операция ясатырга ярыймы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Әйе, сез иреннәрне бер үк размерда итеп, аларның формасын төзәттерә аласыз.

Пластика операцияләре мәсьәләсендә гомуми кагыйдә түбәндәгечә: әгәр мондый операция тышкы кыяфәт җитешсезлеген (тумыштан булган яки яшәү дәверендә барлыкка килгән җитешсезлекне) бетерү өчен эшләнсә, бу рөхсәт ителә.

Әгәр дә операция болай да җитешсезлеге булмаган кыяфәтне төзәтү яки бизәү өчен эшләнсә, бу Аллаһы яраткан, бар кылган нәрсәне, ягъни кешенең табигыйлеген үзгәртү дип санала һәм моны эшләү тыела.

Бу мәсьәләдә нигез булып, тумыштан килгән җитешсезлекне бетерүнең рөхсәт ителгәнлеге турында, хәнәфи мәзһәбе фәтвасы тора. «Фәтава әл-Һиндийә» китабында болай дип әйтелгән:

«Әгәр кем дә булса артык бармагын кисеп алырга яки башка нәрсәне [тумыштан килгән җитешсезлекне төзәтергә] теләсә, Нөсәер (радыяллаһу ганһе) болай дип әйткән: «Әгәр мондый гамәлләрдән соң болай эшләүчеләр еш үлсә, моны эшләргә ярамый, ә киресенчә ешрак уңай тәмамланса – болай эшләргә мөмкин» (5/360).

Мөфти Мөхәммәд Такый Усмани «Тәкъмилә Фәтх әл-мүлхим» китабында болай дип ачыклык кертә: «Артык бармакны һәм шуңа охшаш башка физик җитешсезлекне бетерүгә килгәндә, бу Аллаһы Тәгалә бар кылган әйберләрне үзгәртү дип саналмый, бәлки җитешсезлекне бетерү яки авыруны дәвалау дип атала» (5/116).

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Мосафирмы, юкмы?

**Сорау. Әссәләмү галәйкүм, хәзрәт. Мосафир үзен сәфәрдә 14 көннән азрак булам дип ниятләп чыгып китеп, сәфәре инде 17нче көн дәвам итсә, бу кеше өч көннән өенә кайтасын төгәл белә, аңа намазларын кыскартып укыргамы?**

**Җавап.** Вә галәйкүм әссәлам вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Сезнең очракта, мосафир намазларын кыскартуын дәвам итә, чөнки ул сәфәр халәтендә 15 яки аннан да күбрәк тәүлеккә каласын белмәгән. Димәк, аның нияте тулысынча формалашып җитмәгән булган.

Мондый очракларда, мосафирның теге яки бу җирлектәге сәфәр көннәре, өйгә кайтып китү вакытын төгәл белгәннән соң санала башлый.

Югарыда телгә алынган урында никадәр вакыт яшәвенә карамастан, ул биредә өч көнгә каласын төгәл хәл иткән – менә бу аның мосафирмы-юкмы икәнен билгеләүдә хәлиткеч фактор булып тора да инде.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.



# Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?

**Сорау: Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?**

**Җавап: Әлеге сорауга җавап биргәнче, төгәлрәк булу һәм аңлаешсызлыклардан котылу өчен, «көлү» төшенчәсе белән бәйле кайбер күренешләргә ачыклык кертергә кирәк.**

Шартлы рәвештә, көлүне, намазга йогынты ясау күзлегеннән караганда, өч төргә бүләргә мөмкин:

1. Синең яныңда утырган күршең ишетә алырлык дәрәҗәдә кычкырып көлү.

2. Көлү тавышы яныңда утырган күршеңә ишетелми, көлгәнеңне бары үзең генә тоясың.

3. Көлүгә илтә торган йөз, ирен, күз торышы үзгәрү, әмма, асылда, бу көлү түгел. Әлеге күренеш елмаю дип атала, бу очракта бернинди дә тавыш чыкмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре намазда кычкырып көлү намазны да, тәһарәтне дә боза дигән бердәм фикердә тора. Намаз үтәлгән булып саналсын өчен, яңадан тәһарәт алырга һәм көлү сәбәпле бозылган намазны кабаттан укырга кирәк.

Көлүнең икенче категориясе бары намазны гына боза, тәһарәт бозылмый.

Намаз укыганда елмаю намазны да, тәһарәтне дә бозмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең хаклыкыгын раслаган хәдисне китерик: Җәбир бине Абдиллядан тапшырылган: «Кем дә булса намазда көлсә, намазын кабаттан укысын, әмма тәһарәтне кабат алуга ихтыяҗ юк». (Сахих Бохари, Китабүл вуду, 1/46).

Хәдистә телгә алынган «көлү» ("ضحك") сүзе гомуми мәгънәгә ия һәм ул нинди дә булса сыйфат белән бирелмәгән. Димәк, бу хәдистә яныңда утырган кеше ишетерлек дәрәҗәдә кычкырып көлү әйтелгән дип аңларга кирәкми. Хәнәфи мәзһәбе галимнәре дәлилләре җыелмасында әлеге факт биредә кеше бары үзенең көлгәнен генә ишетә алу турында әйтелә.

Ибне Хөмәм рахмәтуллаһи галәйһи «Фәтхүл Кадир» китабында болай дип әйткән:

«Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне да бозуы хакында хәбәр иткән хәдисләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән берәзлексез иснәд (тапшыручылар чылбыры) белән дә, мөрсәл (табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасында сәхабәне телгә алмыйча) чылбыры ярдәмендә дә килә. Хәдис фәне белән шөгыльләнүче галимнәр, табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасындагы сәхабәне телгә алмыйча, Пәйгамбәр галәйһиссәламнән тапшырылган хәдис ышанычлы тапшыручыдан килсә, аны дөрес дип саныйлар. Әлеге темага мөрсәл хәдисне Әбел Алия, Хәсән Басри һәм Ибраһим Ән-Нәхаи тапшыра».

Шулай ук Ибне Хөмәм рахмәтуллаһи галәйһи: «Бөрәзлексез иснәд (мөснәд) белән килгән хәдисләргә килгәндә, аларны Әбү Муса Әшгари, Әбү Һөрайра, Ибне Гомәр, Әнәс, Җәбир һәм Гыймран бине Хөсәен радыяллаһу ганһүмнәр тапшыра», – дип әйткән.

Бохари хәдисләр җыентыгының танылган «Үмдәтүл Кари» аңлатмасында болай дип әйтелгән: «Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне дә бозуы хакында дәлил сыйфатында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 11 хәдисе бар. Аларның дүртесе мөрсәл (ул табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасындагы сәхабәне телгә алмыйча тапшырыла), ә калган җидесе мөснәд булып тора (өзлексез чылбыр буенча тапшырылган хәдис) («Үмдәтүл Кари», 3 том, 71 б.).

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кайсыгыз да булса намазда кычкырып көлсә, тәһарәтен дә, намазын да яңартсын» (Имам Мөхәммәд, «Әл-Хуҗа», 1/2014; Ибне Гади, «Кәмил», 4/101; Бәйһакый «Әл Хиләфият», 1/389, № 699).

Зәйд бине Халид радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән намаз укыган һәм шул вакытта бер сукыр кеше коега төшеп киткән, бу күренештән берничә сәхабә көлгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам намазны тәгәлләгәч, аларга таба борылып: «Кайсыгыз булса да көлсә, тәһарәтен яңартсын һәм намазын кабаттан укысын», – дип әйткән («Сүнән Дәракутни», 623).

Хәдистән аңлашылганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аларны ишеткәч, димәк көлү тавышы ишетелгән. Һәм бу хәдисне бары шул мәгънәдә аңларга кирәк. Ә Җәбир радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдис аны бары тулыландыру гына булып тора.

Йомгаклап Имам Мөхәммәд бине Әл-Хәсән Әш-Шәйбани рахмәтуллаһи галәйһинең сүзләрен китерәсе килә: «Әгәр дә хәдисләр булмаса, кыяс (аналогия буенча фикер йөртү) нигезендә, барысы да мәлики мәзһәбе галимнәре әйткәнчә булыр иде (ягъни кеше намаз укыганда көлсә тәһарәт бозылмас иде), әмма кыяс мөмкин түгел, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән килгән хәдисләр бар, һәм моңа охшаш барлык очракларда да (аерым алынган темага хәдис булганда), без бары хәдистә әйтелгәнне генә эшләргә тиешбез» (Имам Мөхәммәд, «Әл-Хуҗа», 1/204). Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Булат Мөбәраков,**
**Шәригать бүлегенең җитәкчесе**

# Суфичылыкның мөселманнарның традицияләрен торгызудагы роле

**РФ Иҗтимагый палатасында суфичылыкның Россия мөселманнары традицияләрен торгызудагы роле турында фикер алыштылар**




19нчы февральдә, РФ Иҗтимагый палатасында «Россиянең беренче суфи шәехләре. Россия җәмгыяте рухи үсешенә ислам мирасының керткән өлеше» темасына түгәрәк өстәл узды. Фикер алышу РФ Иҗтимагый палатасының милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр комиссиясе һәм Россия мөселманнары Дини җыены тарафыннан оештырылды. Утырышны Комиссия рәисе Иосиф Дискин һәм аның урынбасары, экстремизмга каршы көрәш буенча эшче төркем җитәкчесе, Россия мөселманнарының дини җыены башлыгы, мөфти Әлбир хәзрәт Крганов алып барды. Түгәрәк өстәл эшендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Россия Федерациясе субъектларының үзәкләштерелгән мөселман оешмалары җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, күренекле галимнәр, экспертлар һәм дин әһелләре, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Әлеге чарада Татарстанны республикабыз мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин тәкъдим итте.

Түгәрәк өстәл барышында катнашучылар суфичылыкның ислам мәгарифенә, хәзерге Россиядә мөселман җәмәгатьчелегенең дини тормышына йогынтысы турында фикер алышты. Моннан тыш, белгечләр Россия мөселманнарының традицион рухи кыйммәтләрен торгызуда суфичылыкның роле һәм әһәмияте, суфичылыкның кешеләрне рухи-әхлакый яктан камилләштерүгә һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлтелгән гуманистик һәм социаль потенциалына караган мәсьәләләр буенча чыгышлар ясадылар. Шулай ук түгәрәк өстәлдә, суфичылык идеяләрен хәзерге Россия җәмгыятенең әхлакый нигезен ныгытуда, этноконфессиональ мөнәсәбәтләр өлкәсендә экстремизмны булдырмау, җәмгыятьтә татулыкны һәм тотрыклылыкны ныгыту өчен файдалануның әһәмияте турында докладлар яңгырады.

Түгәрәк өстәлдә катнашучылар бертавыштан суфичылыкның, дини-фәлсәфи агым буларак, Россиядә исламның аерылгысыз өлеше булуын ассызыкладылар. Ул мөселман дөньясының рухи мәдәниятенә, аның иҗади һәм фәнни фикеренә, фәлсәфә фәненә, әдәбиятка һәм шигърияткә зур йогынты ясаган.

■ **dumrt.ru**

# Балаларыбызга хәләл ризык

***Казан шәһәренең 38 мәктәбе һәм 93 балалар бакчасы хәләл ит ризыклары белән тәэмин ителә***

«Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ мәгълүматлары буенча, Казан шәһәренең 93 балалар бакчасы һәм 38 мәктәбе ярымфабрикат рәвешендәге хәләл ит ризыклары (ит, кош, пилмән, сосиска һ.б.) белән тәэмин ителә. Ит эшләнмәләрен аларга «Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ тапшыра. Әлеге оешмада хәләл продукция җитештерү өчен шартлар тудырылган һәм ул ТР Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты Комитеты тарафыннан даими рәвештә тикшерелеп тора. Казанның кайсы мәктәпләре һәм балалар бакчалары хәләл ит эшләнмәләре белән тәэмин ителә?

■ **dumrt.ru**

**МӘКТӘПЛӘР**

**Авиатөзелеш районы**
60, 62
**Вахитов районы**
131 лицей, 18, 80
**Киров районы**
182 лицей
**Мәскәү районы**
12, 17, 2, 65, 94
**Яңа Савин районы**
146, 155, 165, 85
**Идел буе районы**
16, 18, 19, 35, 68, 83, 83 лицей филиал (95мәктәп)
**Совет районы**
101, 108, 149, 167, 169, 171, 175, 180, 181, 183, 185, 84, 90
**Биектау**
1, 3, 4

**БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ**

**Авиатөзелеш районы**
348ф, 268ф, 366, 404
**Вахитов районы**
188, 273, 273ф, 24, 89
**Киров районы**
82, 133, 134, 81, 122, 321, 91, 81ф
**Мәскәү районы**
126, 126ф, 184, 372, 294д/с при Г-2, 105
**Яңа Савин районы**
110, 208, 28, 315, 99, 99ф, 405, 117, 16
**Идел буе районы**
32, 358, 130, 163, 307, 71, 79ф, 106, 23, 396, 35нче мәктәптәге МББО, 79, 100, 100ф
**Совет районы**
153, 154, 166, 211, 230, 38, 415, 162, 167, 352, 100, 377, 377ф, ДОУ при СОШ 108, 103, 112, 113, 124, 261, 272, 109, 330, 330ф, 394, 398, 399, 40, 402, 54, 60, 64, 67ф, 8, 177, 6, 159, 135, 67, 115, 127, 39, 186, 171ф, 324, 206, 206ф, "Весна"

№2 (295) февраль – 2020
/җөмәдәл-ахыр 1441/



# Татар өммәтенең Ислам үсешендәге роле

**Мөфти БИА Попечительләр советы утырышының нәтиҗәләре турында: "Татарстан һәм татар өммәте - илебездәге Ислам үсешенең иң уңышлы моделе"**

8 нче февральдә Болгар ислам академиясендә Попечительләр советының тәүге утырышы узды. Утырыш РФ Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко рәислегендә һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, шулай ук илнең берничә төбәге башлыклары һәм иң эре эшмәкәрләр катнашында узды. Җыелышта шулай ук Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасарлары Илфар хәзрәт Хәсәнов (ул БИАның Учредительләр советы рәисе дә) һәм Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин (БИАның беренче ректоры һәм Рәсәйнең ислам мәгарифе советы рәисе) да эшләделәр.

Сәламләү сүзендә Сергей Кириенко ассызыклаганча, Рәсәй Президенты традицион ислам белеме мәктәбен үстерү бурычын куйган иде. "Безнең илебездә ислам тарихы бай, аның күп гасырлы мәдәнияты, үз традицияләре бар. Бу Рәсәй кебек күп милләтле һәм күп конфессиональ ил өчен бу аеруча мөһим. Рәсәй исламының үзенчәлекле традицияләре сакланып, дин әһелләренең яңа буыннарына тапшырылып килде", - диде ул.



Аның сүзләренчә, Рәсәй Президенты Болгар ислам академиясенә ярдәм, Ислам мәдәнияты, фәнe һәм белеме фондын финанслауны арттыру буенча берничә карар кылды.

Рөстәм Миңнеханов чыгышында билгеләгәнчә, 922 елда исламны кабул итү уникаль Евразия цивилизациясе формалашуының төп этабы. "Ислам дине белеменең мең еллык традицияләре бар. Бабаларыбыз калдырган бай мирасыбыз XIX гасыр - XX гасыр башындагы мәгърифәтчеләребез һәм дин әһелләребез хезмәтләрендә лаеклы чагылыш тапты", - диде ТР Президенты.

Ул ассызыклаганча, төпле карарлар кабул итү дини өлкәдәге проблемаларны хәл итәргә ярдәм итте. Кабул ителгән карарлар арасында Рәсәй ислам университетын оештыру, исламны тирәнтен өйрәнү чаралары буенча федераль план, ислам белеме Советын оештыру бар. Рөстәм Миңнеханов шулай ук Ислам мәдәнияты, фәнe һәм белеме фондының тәэсире дә зур булуын ассызыклады. ТР Президенты сүзләренчә, Болгар ислам академиясен оештыру шул зур эшнең логик дәвамы булды. Ул алдынгы ислам фәнни-мәгариф, дини белем үзәге булырга тиеш.

Алга таба эшчәнлекнең нәтиҗәләре турындагы хисап һәм мөһим юнәлешләре хакында академиянең ректоры Данияр Абдрахманов чыгыш ясады.

Утырыш нәтиҗәләре буенча Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин болай дип белдерде: "Җыелышның шундый югары дәрәҗәдә үтүе дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан Рәсәйдә ислам мәгарифен үстерүдә һәм заманында Рәсәй мөселманнарын Ислам дөньясының иң алдынгы өммәтләре дәрәҗәсенә күтәргән тарихи нигезләрне яңартуда кызыксынуын дәлилли. Һичшиксез, Татарстан һәм татар өммәте - илебездәге Ислам үсешенең иң уңышлы моделе. Бу модель шуны күрсәтә: дини, фәнни, хакимият һәм коммерция оешмалары көчләрен берләштергәндә генә уңай үзгәрешләр булырга мөмкин".

ТР Президенты матбугат хезмәте материалы һәм фотолары файдаланылды.

■ **dumrt.ru**



# Яулыклы кыз

Автобуска янып-пешеп мөселман кызы килеп керде. Үзенең самими карашы һәм әлеге маршрутка өлгергәненә чиксез шатлануы күзләрендә чагыла иде. Кайберәүләрнең үзенә төбәлгәнен сизгән кыз, оялып кына башын иде. Белмим, кемнәр ничектер, әмма минем янәшәмдә баручыларның аңа сокланып карауларын сиздем. Тик, кем белән бәхәскә керим икән, дигәндәй барган кырыс карашлы ханымга гына нидер ошамады. Һәм ул мөселман кызын баштанаяк «тикшереп» чыкканнан соң:

– Сез бик яшь бит әле. Нигә болай төренеп йөрисез? – дип куйды.

– Апа, без – мөселманнар. Шуңа да Аллаһы кушканча яшәргә тырышабыз, – дип, тыныч кына сүзен башлады кыз. – Изге Коръәнебездәге Нур сүрәсенең 31 нче аятендә: **«Әйт мөэминә хатыннарга, карарга ярамаган нәрсәдән күзләрен йомсыннар һәм гаурәтләрен зинадан сакласыннар һәм кул белән йөзләреннән башка булган зиннәт урыннарын ачмасыннар, мәгәр һәрвакыт ачык була торган йөзләрен, ике кулларын һәм тәпиләрен ачсалар ярый…»**, – диелгән. Шуңа да моны бер кагыйдә, канун итеп кабул итеп, аңа буйсынабыз. Башкача эшләргә хакыбыз да юк. Монда, син яшь, кияүгә чыккач ябарсың, лаеклы ялга чыккач «төренерсең», дигән сүзләр булырга тиеш түгел. Моңа һәр кыз бала үзе килә. Һәм бу аның өчен файдага гына. Яулык хатын-кызны чикли, кимсетә, диюләре дә дөрес түгел. Яулык аны бары саклый гына.

– Ничек саклый инде ул сезне? Төренеп йөрисез шунда, – дип бәйләнүен дәвам итте ханым.

– Ә сез күз алдыгызга гына китереп карагыз әле. Кайбер хатын-кызлар, күп кенә яшь кызлар ачык, сыланып, гаурәтләрен күрсәтеп торган кием киюләре сәбәпле, ир-атларның игътибарын үзләренә җәлеп итә. Кызганычка, кайберәүләр әлеге гамәлләре белән башларына кайгы да ала. Исламда ир-ат хатын-кызга хөрмәт белән карарга, сөйләшкәндә йөзенә карап сөйләргә тиеш. Ул хатын-кызга нинди дер әдәпсез тәкъдимнәр ясаудан ерак тора. Үзенең матурлыгын, нәфислеген каплаган хатын-кыз үзенә беренче чиратта шәхес итеп карауларын таләп итә. Киемнәре, үз-үзен тотышы һәм сөйләшүе белән ул ир-ат алдында хөрмәткә лаек зат буларак хисаплана.

– Барыбер болай йөреп, егетсез дә, ирсез дә каласыз бит. Капланып йөргәч, кем күрсен сезнең матурлыкны? – ди әңгәмәдәш, өстән карарга тырышып.

Яулыклы кыз елмаеп куйды.

– Нигә алай дисез? Мәсәлән, мин инде кияүдә. Үземне ярата, хөрмәт итә, авыр чакларда таяныч булучы мөселман егетен тормыш юлдашы итеп сайладым. Мине кияүгә алганда ул беренче чиратта минем эчке дөньяма, Ислам кануннары буенча яшәвемә, Аллаһыга мөнәсәбәтемә игътибар итте. Бик күп мөселман кардәшләрем белән дә шулай ук. Кияүгә алмыйлар, дигәнегездән көләсем килә. Бик кызык тоела бу миңа. Әгәр дә мөселман кызы Аллаһы кушканча яши, Аңа гыйбадәт кыла, үзен әхлак кысаларында тота икән, нигә әле аңа үзе кебекләр игътибар итмәскә тиеш?! Бер дус кызымның әтисенә бер үк вакытта ике егет кызының кулын сорап килде. Ахыр чиктә, кыз үзенең йөрәгенә якын булган егетне сайлады. Һәм бүген дә үкенми. Ә кире борылган егет үпкәләми, чөнки бу кызның хокукы иде.

– Ә мин сездә әти-әни кызларын үзләре теләгән кешегә генә бирәләр һәм кыз телиме-юкмы, ата-ана кушканча эшли, дип белә идем, – диде ханым, беркадәр югалып калып.



Мөселман кызы өчен бу сүзләрнең көлкеле тоелуы йөзенә чыкты. Моны яшерергә тырышып, ихтирам белән әңгәмәсен дәвам итте ул:

– Сез әллә кызны бикләп куеп, үз ихтыярына каршы килеп, ирекләрен кысалар һәм аның фикерен тыңлап та тормыйлар дип белдегезме? – дип, сорады ул, әңгәмәдәшен фикерләргә мәҗбүр итеп – Сезнең Ислам турындагы фикерләрегез башта мине гаҗәпкә калдырса, инде бу фаразлауларыгыз миндә көлке тудыра. Бездә беркемне дә үз ихтыярыннан тыш кияүгә бирмиләр. Динебездә, гомумән алганда, көчләү юк. Бу теләсә нинди шәригать канунына кагыла. Кеше гамәлне үз теләге белән башкарган очракта гына ул ихластан, Аллаһы ризалыгы өчен эшләнгән була. Тагын шул ук яулыкка килик: хатын-кыз, миңа ирем яулык бәяләргә куша, үземнең бер дә болай йөрисем килми, ди икән, димәк, йә әле ул моңа әзер түгел, йә яулыкның тиешлеге, кирәклеге, фарызлыгы турында аңа дөрес аңлатмаганнар. Элеккеге сөйләшүгә кайтыйк. Мәсәлән, мөселман егете белән кызы, бүгенге күп кенә яшьләр кебек, уку йортларында танышып киткәләр икән, икесе дә бер-берләрен күңелләре белән якын итсәләр, егетнең әти-әнисе кызны, кызныкылар егетне үзләренең балалары өчен хәерле дип күрсә (ә бу күп очракта шулай була), егет ата-анасы белән кызның кулын сорарга килә. Никах дигән бик әһәмиятле, күркәм мәҗлес уза. Туганнар, якыннар, дуслар җыела. Яшь парны бер-берләрен табулары белән котлап, Аллаһы алар өчен хәерлесен генә бирүне сорап, дога кылына. Ә инде келәшнең әтисеннән кызын сорап килүчеләр булса, ата кеше беркайчан да, кызының риза булмаячагын белә торып, үз теләге белән генә хәл итми. Аның өчен кызының һәм сөекле тормыш иптәшенең фикере мөһим урын алып тора. Ә инде үзенең кызына нәрсә хәерле, нәрсә яман икәнен белүче ата кеше, һәрвакыт үзенең белдеклелеге, тормыш тәҗрибәсе белән эш итә. Кызына бәхет кенә теләүче әти аны теләсә кем белән кавыштырмый. Әгәр тарихтан укып белсәгез, элек, Ислам дине килгәнче, әхлак-әдәп нормалары гамәлгә кергәнче кыз өчен җаваплы булучы, (Исламда ул «вәли» дип йөртелә) безнең мисалда, әти кеше, байлыкка кызыгып, кызын әллә кемнәргә дә бирергә риза булган. Ә Ислам өчен бу ят күренеш.

Шушы бәхәскә кереп китүенә инде үкенә башлаган ханымга янәшәдәгеләр тискәре караш ташлады: «Бәйләнмәгезче кызга», «Тыныч кына бара белмисезме әллә?» – диеште алар. Ә яулыклы кыз килеп кергәндә нинди ягымлы күзләр белән караса, шундый ук самимилек белән ишеккә таба атлады. Киләсе тукталышта төшеп калырга тиешле иде ул. Үзен сораулары белән түбәнсетергә теләгән ханымга борылып: «Сезнең тормышта бар да яхшы булуын һәм үзегезне борчыган сорауларыгызга җавап табуыгызны телим», – дип саубуллашты. Ә тегесе бер сүз дә эндәшмичә, бер ноктага гына төбәлгән иде. Кызның күзләре, карашы, адымы, үз-үзен тотышы автобус салонындагыларда бары горурлык хисләре генә тудырды. Тукталышка килеп җиткәч, төшәм генә дигәндә, аның кулларына берәү йомшак кына орынды. Бу ишек янындагы урындыкта утыручы мөселман карчыгы иде. Ул елмаеп яулыклы кызга карады. Аны кызның Исламны шулай дөрес итеп аңлатуы һәм ханым алдында югалып калмавы гаҗәпләндергән һәм сокланландырган иде. Шуңа да әбинең күзләрендәге яшь бөртекләрен күреп кыз ничектер каушап китте.

**■ Ләйлә Әхәтова**

# Япониянең беренче мөселманнары: Нагоя шәһәре татар җәмәгатьчелегенең тарихы



Татарларның Япониягә күченү тарихы



1998 елда ачылган мәчетнең бүгенге көндәге күренеше

Әлеге мәкалә Япониянең Нагоя исемле шәһәрендәге татар җәмәгатьчелегенең тарихына багышлана. Япониядә беренче татарлар якынча XX гасыр башында барлыкка килә, ә 1917 елгы революциядән соң аларның саны тагы да арта. Бирегә килүче татарларның күпчелеге тукыма һәм кием белән сату итүче сәүдәгәрләр була. Япония, Аурупа өчен ябык булганга, әмма Аурупа киемнәренең фасоны һәм тукымалар җирле халыкта зур кызыксындыру тудырганга күрә, әлеге эшмәкәрләргә монда сәүдәләрен үстерү өчен зур мөмкинлекләр ачыла.

Алга таба, сәүдә эшләрен җайга салгач, күченеп килүчеләр Япониягә, нигездә Маньчжуриядән булган башка татарларны да чакыра башлый. Шулай итеп Йокохамада, күпмедер вакыттан соң, Токио, Кумамото, Кобе һәм Нагоя шәһәрләрендә беренче татар җәмәгатьчелеге оеша. Ел саен җәмәгатьчелектәге кешеләр саны артканлыктан, үзләренең мәчетләрен һәм мәктәпләрен ачу зарурлыгы туа. Әгәр дә баштан татар җәмәгатьчелеге әлеге максатларда аерым биналар арендалаган булса, соңрак, акча ягыннан ныгыгач, җирләр сатып ала һәм анда аерым мәчетләр, мәктәпләр төзи башлый. Әлеге татар-мөселман җәмәгатьчелекләре ярдәмендә японлылар беренче тапкыр якыннан Ислам дине белән таныша.

Нагоя шәһәре һәрвакытта да Япониянең порт шәһәре булып торган. Моннан тыш, Нагоя янында Кобе һәм Осако шәһәрләре кебек индустриаль үзәкләр урнашкан була. Мөгаен, нәкъ менә әлеге фактлар 1919 елда Нагояда кайбер татар гаиләләренең төпләнүенә сәбәп буладыр. Алар әлеге шәһәрдә төпләнеп, яши башлаучы беренче мөселманнар булалар. Шәһәр аралары якын булганлыктан, Нагоя татар җәмәгатьчелеге Кобедагы кардәшләре белән тыгыз элемтәдә тора. Бу зур булмаган, әмма бик тә бердәм җәмәгатьчелек була. 1919 елдан алып, 1945 елга кадәр татар җәмәгатьчелегендә, балаларны санамыйча, 30 дан алып, 60 ка хәтле кеше исәпләнгән.

Татарлар һәрвакытта да диндар булулары белән аерылып торганнар, шуңа күрә кая гына күченеп яши башласалар да, беренче эш итеп, мәчет төзергә тырышканнар. Әҗәмәгатьчелекнең иң укымышлы әһелен имам итеп билгеләгәннәр. 1931 елда җәмәгатьчелек «Нагоя мөселманнары җәмәгатьчелеге» дип исем алып, рәсми рәвештә теркәлү уза.

Җитәкче буларак Әхмәд мулланы билгелиләр. Туган якларыннан читтә яшәгән балалар үз телләрен, мәдәниятләрен һәм диннәрен онытмасыннар, дигән фикерне алга сөреп, җәмәгатьчелек үз алдына балаларны укыту мәсьәләсен куя. Моның өчен 1933 елда җәмәгатьчелек әһелләре махсус биналар арендалый һәм укытучылар чакырта башлый. Шушы ук бинада (Бунка Киокай) татар мәдәнияте үзәге нигезләнә.

Елдан-ел балалар саны артканлыктан, күпмедер вакыттан соң, мәктәптә урын җитми башлый. 1935 елгы март аеның җәмәгатьчелек җыелышында мәчет төзү турындагы карарны кабул итәләр. Мәктәп әлеге мәчет бинасында урнашырга тиеш була. Оештыручылар алдында, беренче булып, Япония хөкүмәтеннән рөхсәт алу бурычы тора. Хакимият органнарына җәмәгатьчелекнең мәнфәгатьләрен белдерер өчен тулы хокуклы вәкилләр билгеләнә. Бу вазыйфаларны үз өстенә Тимербай Хәмидулла һәм Хөснетдин Саидгалиев ала. Шулай ук мәчет төзү өчен түбәндәге составта комитет оеша: Тимербай Хәмидулла – комитет рәисе; Хөснетдин Саидгалиев – казначы; Мансура ханым – сәркатип; Сизган – рәис урынбасары; Хөсәен Кильки – комитет әгъзасы, шул ук вакытта җәмәгатьчелекнең җитәкчесе һәм имамы; Г. Шихатер – комитет әгъзасы.

Җир алыр һәм төзү эшләрен башлар өчен акча җыю эше оештырыла. Ул вакытта Нагоя шәһәрендә бары тик 12 мөселман-татар гаиләсе яшәгәнлектән, кирәкле сумманы җыю аларның көчләреннән килми. Җәмәгатьчелек әһелләреннән тыш, күпчелек финанс ярдәмне Япониянең һәм Маньчжуриянең башка татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, шулай ук һинд мөселманнары һәм Кобе гарәпләре күрсәтәләр.

1936 елның апрель аенда җәмәгатьчелек 16 Banchi 25, 3 Chrome, Chikusa-ku адресы буенча җир сатып алса да, төзү эшләрен башлар өчен акча җитми. 1936 елның гыйнвар аенда Нагояга, үзенең гаиләсе белән, Кобе шәһәре татар җәмәгатьчелегенең лидеры Гисмәтулла Эгердҗи килә. Ул төзү эшләренә, дип, ул вакыт өчен бик күп саналган, 1 000 йен акча бүлеп бирә. Шул ук елның август аенда җәмәгатьчелек, ниһаять, төзү эшләрен башлар өчен, рәсми рәвештә рөхсәт алуга ирешә.

1936 елның 4 нче сентябрендә тәүге таш куюның тантаналы чарасы оештырыла. Чарада, җәмәгатьчелек әһелләреннән тыш, Кобе шәһәре имамы Мәдьяр хәзрәт Шәмгуни, Һиндстан мөселман дин белгече Мәүләнә Мөхәммәд Габдулалим Сыддыйк катнаша.

Мәчет тантаналы рәвештә 1937 елның 22 нче гыйнварында ачыла. Шунысы да игътибарга лаек: бу – Япониядә төзелгән икенче мәчет була (беренчесе Кобе шәһәрендә урнашкан). Кызганычка, бу вакыйгаларга куану озакка бармый. Япония, 1941 елның 7-8 декабрендә, Тын океанындагы (Перл-Харбор) Америка корылмаларына, Азиядәге (Гонконг) Бөекбритания корылмаларына һөҗүм итеп, Икенче Бөтендөнья сугышына кушыла.

1945 елның март аенда Нагоя татарлары шәһәрдән китәргә һәм Кобедагы кардәшләренә күченергә мәҗбүр була. Җәмәгатьчелек әһеле Рөстәм Арсланов сүзләре буенча бу күченү мәҗбүри рәвештә эшләнә һәм Япония җитәкчелегенең таләп итүе белән бәйле була. Ул вакытта Япония белән Кушма Штатлар арасында киеренке сугыш бара. Нагоя янында хәрби заводлар урнаштыралар, шулай ук гаскәрләр һәм авиация туплана. Мөгаен, японлылар, татарлар дошманга әһәмиятле мәгълүматлар тапшырырга мөмкин, дип уйлагандыр. Биредәге татарлар инде күптәннән японлыларга кушылган булуга карамастан, Япония җәмгыяте аларны элеккеге Рәсәй империясе кешеләре итеп кабул итә. Империя варисы – Советлар Союзын, Япония хөкүмәте, дошман һәм Кушма Штатлар союздашы дип исәпли.

Билгеле булганча, америкалылар тарафыннан һөҗүм ясалган вакытта, Нагоя мәчетенә бомба төшә һәм ул тулысынча янып бетә. Соңрак, 1950 елларда, авыр экономик шартлар аркасында Япониянең күпчелек татарлары Төркия, АКШ, Канада һәм Австралиягә күченә.

Нагоя җәмәгатьчелегенең бүгенге көн мөселманнары 1998 елның июль аенда яңа мәчет ачу бәхетенә ирешә. Зур булмаган әлеге дүрт катлы мәчет дөньяның иң үзенчәлекле мәчетләренең берсе булып тора. Мәчеттән тыш, бинада ислам үзәге эшләп килә.

■ **Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**

# Ислам динендә хатын-кыз

Техника үсеше һәм яңартылу чорында яшибез. Тормыш гөрли, алга чаба. Артта калмас өчен адәм баласы бөтен көчен куеп эшли, белемен ныгыта, сәламәтлеген кайгырта. Ләкин шул вакытта ул рухи яктан үзен кайгыртмый башлый, әкренләп кешедә тормышыннан канәгатьсезлек хисе уяна башлый. Мондый халәттә адәм баласына дин ярдәмгә килә, чөнки бары тик Аллаһыга гыйбадәт кылу гына рухи тынычлык бирә ала. Көне буе чабып, арып-талып кеше өенә тынычлык эзләп кайта. Өендә ирне мөслимә тормыш иптәше көтсә, димәк бу йортны чыннан да тынычлык, мәхәббәт оясы дип әйтеп була.

Хатын-кыз ир-ат тормышында 4 рольне башкара: ана, хатын, апа (сеңел) һәм кыз бала. Һәрбер роле ир кеше яшәешендә зур әһәмият алып тора.

Әгәр дә хатын-кызның хатын буларак ролен карасак, иманлы тормыш иптәше гаиләдә балаларны Ислам динe кушканча тәрбияләп үстереп, иратны иманлы, итагатьле балалар белән шатландырачак. Сеңел яисә апа буларак ул абыйсына төрле тормыш авырлыкларын җиңеп чыгу өчен терәк булачак. Кыз бала буларак әтисен кайгыртып яшәячәк. Шулай итеп, ир кеше бәхетле булсын өчен аңа төрле яктан хатын-кыз терәге, мәхәббәте кирәк дигән нәтиҗә ясап була.

Ислам дине хатын-кызны үзенчәлекле итеп ир-аттан аерып куйды. Ләкин моны хатын-кызның хокукын чикләү дип түгел, ә Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләнең аңа булган кайгыртуы, мәхәббәте дип аңлау тиешле. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Әй, мөэминнәр, хатыннарны көчләп, мирас урынына тоту сезгә хәләл түгел».**

«Нисә / Хатыннар», 4:19

Шул рәвешчә Раббыбыз ирләргә хатыннарын кадерләргә куша.

Хатын-кызның ире алдында бик күп бурычлары бар. Аларны үтәмәгән очракта Аллаһының ачуына дучар булуын да бөтенесе дә аңлый, моның турында күп языла. Бүген без ир кеше гаиләдә бәхетле булсын өчен нинди чаралар барлыгын карап үтәчәкбез.

Гокбә бине Әмир хәбәр итә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Ныклап үтәлергә тиешле шартлар шул – ул якынлык кылуны рөхсәт итүче шартлар» (Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдис җыентыкларыннан).

Мулла Әл-Кари бу хәдисне болай аңлата: «Шарт дигәннән, без монда мәһәрне кузалларга тиешбез, чөнки аны түләп, без тормыш иптәшебез белән якынлык кылырга хокук алабыз. Башка галимнәр болай дип әйтә: «Монда сүз никахтан соң хатын-кызның нинди хокукларга ия булуы турында сүз бара. Болар мәһәр, тәэмин итү һәм яхшы мөгамәлә», – диләр.

Димәк, өйләнешкәч, ир-ат та үз өстенә зур гына йөкләмәләр ала икән. Кызганычка, бүгенге көндә ир-атның гаиләсенә карата яхшы мөгамәлә һәм кирәкле кадәр игътибар бирүе чын ир кеше эше дип саналмый башлады. Киресенчә, андый ир-ат өстеннән «хатын кубызына биюче» дип мәсхәрәләү гади күренеш.

Әгәр дә инде ул берничә көн буена өендә дә күренмичә кафе һәм рестораннарда йөрсә, хатыны һәм туганнары да аның кайдалыгында хәбәрдар булмасалар бу «чын» ир дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма, дөреслектә, монда ирлекнең тамчысы да күренми.

Гаилә ул – ике кешенең бәхетле гаилә төзүдә уртак хезмәте, бердәмлек булмаса, нәтиҗә дә юк дигән сүз. Ничәмә-ничә еллар шул кеше белән бер түбә астында гомер итеп, ул кешедә сиңа карата бары тик нәфрәт хисе генә калса, бергә яшәүнең нинди мәгънәсе кала?

Гаилә – ул, беренче чиратта, берберең юл кую өстендә эшләү. Әбү Һөрайрадан җиткерелә: «Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәләдә булыгыз диеп әйтеп калдырам. Дөреслектә, хатын-кыз кабыргадан яратылды, кабырганың иң кәкре җире – өске ягы. Турайтырга уйласаң, сындырырсың, ничек бар шулай калдырсаң ул тураймаячак. Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәләдә булыгыз дип әйтеп калдырам», – дип әйткән (Имам Бохари һәм имам Мөслим җыентыкларыннан).

Бу сүзләр алар үзгәрер дигән фикер белән яшәмәскә, аларның «кәкрелеген» кабул итеп, алар янәшәсендә булуны аңлата. Яшьләр гаилә корып бераз вакыт үткәч, бер-берсен өйрәнү, иләнү чоры башлана. Менә монда инде ир кеше хатын-кызны төзәтергә кирәк дигән фикер белән яна башлый. Бу бер дә яңалык түгел, чөнки моны Пәйгамбәребез дә шулай булачак дип әйтеп калдырды. Монда инде «алтын» урталыкны югалтырга ярамый: әлбәттә, хатын-кыз ир кешегә яраклашырга тиеш һәм ир кеше дә моны әйтмичә, исенә төшермичә тора алмый, әмма чикләрне узарга да ярамый. Кимчелекләргә сабыр итәргә, ачу китерә торган гадәтләр белән килешергә кирәк. Бер хатын-кыз озак җыена, икенчесе кире, өченчесенә берәр төрле ризык ошамый һ.б. Шуның ише вак кимчелекләргә сабыр итәргә тиешле, чөнки бу кимчелекләрне «сындыра» башласаң бу аерылышуга китерәчәк.

Бүгенге көндә бу хәдис бик актуаль. Безнең балалар һәр шәхеснең үз фикере булган чорда яши, хәтта мөселман гаиләсендә туып-үскән балалар да моннан читтә калмый. Бер-береңә юл кую дигән төшенчә күп очракта яшьләр өчен бөтенләй ят әйбер.

Имам Ән-Нәвәви болай дип әйтә: «Бу хәдис хатын-кызга карата йомшаклык күрсәтергә, аларга карата яхшы мөгамәләдә булырга, аларның начар холкына сабыр итәргә өнди, чөнки аларның акылы зәгыйфь, ә алардан сәбәпсез аерылу мәкруһ һәм аларны үзгәртү өметсез».

Әлбәттә, юл кую килү дини мәсьәләләргә һәм гөнаһ эшләр кылуга китерергә тиеш түгел. Мәсәлән, үзең намаз укып хатының гауратләрен капламыйча йөрсә, «мин сабыр итәм» дип кенә Аллаһы каршында акланып утырып булмаячак.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Иманлы кешенең мөслимәгә карата нәфрәт хисе булырга тиеш түгел. Әгәр аның берәр сыйфаты ошамаса, икенчесе, һичшиксез, күңеленә хуш киләчәк» (Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Бу хәдистән без хатын-кызның кимчелексез булмаячагын күрәбез. Әгәр дә ир кеше кимчелексез тормыш иптәше эзли башласа, ул беркайчан да өйләнмәячәк дип ныклап әйтеп була. Кешенең бер генә булса да яхшы сыйфаты булмыйча калмый, шулай булгач, аннан начар якларны эзләмичә, яхшы якларын күрә белергә кирәк. Ир белән хатын-кызга тормыш баткаклыгыннан күтәрелергә тырышырга тиешле. Синең янәшәңдә Аллаһыга һәм Пәйгамбәребезгә ышанучы кеше һәм аның сиңа ошаган, синдә горурлык уяткан сыйфатлары булмау мөмкин түгел.

Парлар башкаларның тормышына кызыгырга, бер-берсе алдында аларны мактарга тиеш түгел, чөнки ябык ишекләр артында нәрсә барын беркем дә белми. Ә бу гамәл бер-береңә карата нәфрәт уятырга мөмкин.

Шулай ук бер нәрсәне истән чыгарырга кирәкми: ә син үзең нинди, синдә башка кешедә күрә алмаган нинди сыйфатлар бар? Синең бу сыйфатларың хатыныңда ачу, нәфрәт хисләре уятмыймы икән? Бу хәдис гаилә «бер капкалы уен» гына түгел, ә икеңнең дә хезмәте дигәнне аңлата.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә барчаларыбызга да күркәм гаилә булып, бер-беребезне яратып, хөрмәт итеп яшәргә насыйп итсен. Балаларыбыз безнең көзгебез, алар бәхетле булсын дисәк, гаиләдә тынычлык, ихтирамлылык, сабырлык урнаштыру безнең бурыч, җәмәгать!

■ **Илгиз хәзрәт Әшрапов,**
**Яңа Чишмә районы мөхтәсибе**

# Тарихта эзләләр...

### Гайшә радыяллаһу ганһә!

Гайшә радыяллаһу ганһә бик юмарт булган. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган.

Бервакыт ул ураза тоткан көнне аңа йөз мең дирһәм биргәннәр. Ул акчаны бүлгән дә, мохтаҗларга тараткан. Гайшә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: «Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка хатын-кызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый һәм һәрвакытта да җавап таба идек». Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 2210 хәдис тапшырган.

### Зәйнәб бинте Җәхеш радыяллаһу ганһә!

Пәйгамбәребез үрнәгенә ияреп, Зәйнәб юмарт һәм тыйнак була. Шулай көннәрнең берендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык хатыннары барында: «Миннән соң сезнең иң озын кулларыгыз миңа иярәчәк», – дип әйткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән соң беренче булып Зәйнәб бинте Җәхеш үлгән. Шул вакытта Пәйгамбәр хатыннары аның «иң озын куллы» (юмарт) булуын белгәннәр, чөнки Зәйнәб кул эшләрен яратып башкарган (тире эшкәрткән, куннән киемнәр теккән, дисбеләр ясаган) һәм ярлыларга шул малдан садакалар тараткан. Бу гамәлләрен ул барысын да Аллаһы ризалыгын өмет итеп башкарган. Өмме Сәләмә Зәйнәбнең үлеменнән соң: «Зәйнәб бик тугры хатын иде. Бик еш уразалар тотты һәм бик күп кул эшләре белән шөгыльләнде һәм шул рәвешле эшләп тапкан акчасын ярлыларга таратты», – дип әйткән.

# Бәхетеңә киртә корма

**Үз бәхетебезгә үзебез киртә кормыйча, уйлана, нәтиҗәләр чыгара һәм бәхетле булырга өйрәнсәк иде.**



Кеше бәхетсезлегенең төп сәбәпчесе – аның бәхетле булырга теләмәве. Кызык яңгырый һәм аңлашылмый, билгеле. Әмма бу сүзләрнең мәгънәсе бар. Бу сүзләргә дин ягыннан игътибар бирсәк, аның нинди фикерләргә таянганын аңларбыз.

Еш кына кеше үз бәхетенә үзе каршы чыга, үзенең нинди бәхетле икәнен аңларга, танырга теләми. Бәхет төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый. Берәүләр өчен ул, байлык, икенчеләр өчен дәрәҗә, өченчеләр өчен матурлык, уңышка ирешү, танылган булу һ.б. Мондагы исемлекне тагы да тулыландырып була, әмма мин берсен генә мисал итеп китереп үтәм.

Әйе, бик күп кеше бәхетне материаль яктан җитеш тормышта яшәүдә күрә. Әмма бәхет – ул тотып карый торган материаль әйбер түгел. Кеше тормышының билгеле бер этабында материаль яктан авырлыкларда яшәсә дә, үзен бәхетле тоярга һәм җитеш тормышта яшәгән вакытта да күңеленә тынычлык, рәхәтлек тапмыйча яшәргә мөмкин. Күпләр тормышның мондый очракларында калганы бар. Килешәсезме, чыннан да, кеше бөтенләй дә бәхетле булырга «тиеш булмаган» вакытта бик бәхетле гомер кичерергә мөмкин һәм киресенчә.

Димәк, бәхет күпкә зуррак, мәгънәлерәк төшенчә. Бәхет – ул халәт, ул кешенең эчке дөньясыннан риза булып, канәгать йөрүе.

Шуңа да кайбер кеше бәхетне саулык-сәламәтлектә, күңел тынычлыгында, үзе яшәгән җирлектә иминлек-тынычлык хакимлек итүендә, өсте бөтен, тамагы тук булуда күрә. Менә шушы төшенчәләр бәхет хакындагы билгеләмәгә якынрак та инде. Тик монда да үз нечкәлекләре бар.

Динебез Исламда һәрбер сорауга җавап әзер. Әгәр уйлансак, кеше тормышын, аның күзаллауларын, бу дөньяга карашын тәртипкә китерер өчен берничә аятьне һәм хәдисне үзеңә (шигар) девиз итеп алу җитә. Тик бу, укыдым да – оныттым булырга тиеш түгел. Шуларның берничәсен карап үтик:

1. **«Шиксез, Ул – Аллаһы барча мәхлукатны ризыкландыручы вә бик олуг куәт ияседер».**

«Зарият / Таратучы», 51:58

Кеше тормышында югарыга меңү чорлары да, түбәнгә тәгәрәү вакытлары да була. Көчле рухлы мөэмин-мөселман һәрвакыт авырлыкларның вакытлыча гына булганын һәм Аллаһыдан сынау икәнлеген аңлый, сабырсызлык, ашыгучанлык күрсәтми. Хәтта Җир йөзендәге барлык кеше аңа каршы булган очракта да, Аллаһының рәхмәте булса, Ул колын ташламаячак, ризыксыз калдырмаячак.

2. **«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Тормышының иң авыр вакыты дип уйлап, төшенкелеккә бирелгән кеше Коръәндәге әлеге аятьне исенә төшерә. Әгәр дә сиңа берәр авырлык килде икән, бел: Аллаһы адәм баласына күтәрә алмаслык сынау бирми. Сорау бер: ул сынау аңа нәрсә өчен бирелде һәм аны лаеклы рәвештә үтәр өчен нишләргә?

3. **«Һичшиксез, (чиккән һәр) авырлыктан соң җиңеллек бар».**

«Инширах / Ачмак», 94:5

Булган борчу-мәшәкатьләреңнең очы-кырые күренмәгәндә, бу аятьне исеңә төшер. Һәр авырлыктан соң җиңеллек килә, яңгырдан соң салават күпере чыга.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәламнең хәдисләре кешенең бәхеткә, гомумән тормышка карата булган карашын уңай якка үзгәртә, уй-фикерләрен тәртипкә китерә.

Кайбер хәдисләрне карап үтик:

1. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия кеше кебек булыр», – дип әйткән.

Гадәттә адәм баласы иртә белән күзен ачу белән үк көн дәвамында хәл итәсе проблемаларын, борчу-мәшәкатьләрен исенә төшерә. Еш кына әллә нәрсәләр уйлап, үзенчә фаразлап, үзен җир йөзендәге иң күп авырлыклары булган кеше итеп фикер йөртә башлый. Бер мизгелгә генә туктальйк әле. Без сау-сәламәт көе, иминлектә йокыдан уяндык. Ә йокыдан уяна алганбыз икән, димәк, безгә Аллаһы Тәгалә тагын бер көн гомер биргән. Һәм аны ничек үткәрүебез безнең бары үзебездән генә тора. Йокыдан уяну-уянмавыбыз Аллаһыдан торса, көнебезнең ни рәвешле узачагы бары безнең үзебезгә бәйле. Көн дәвамында юкка-барга зарланып йөрибезме, әллә Аллаһыга булганына шөкер итеп, яңа туган көннең ямен күрергә тырышабызмы?! Һәркем үзенчә хәл итәчәк, билгеле.

2. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Үзегездән югары булганнарга түгел, ә түбән булганнарга карагыз. Бу сезгә Аллаһы сезгә биргән нигъмәтләрне ким итеп күрмәскә булышыр», – дип әйткән.

Еш кына адәм баласы шөкерсезлек күрсәтә. Инсан дигән сүз дә гарәпчәдән нәсийә, ягъни онытучы, дип тәрҗемә ителә. Кеше Аллаһының биргән нигъмәтләренең кадерен белми, ә кадерен белеп, рәхәтен күреп яшәгәндә авырлыклар килсә, бәхетле чакларын бик тиз оныта. Бүген җитеш, мул халәттә яшәп, иртәгә берникадәр авырлыклар белән очрашса, зарлана башлый, үзен иң бәхетсез кеше дип саный. Ә бәлки кеше, тормышының бу вакытларында аннан да авыррак хәлдә калучылар барлыгын истә тотарга тиештер?! Ә бәлки бүген кеше ия булган, әмма кадерен белмәгән нигъмәтләр турында берәүләр көн-төн Аллаһыга дога кылып ялвара, шуның хакта хыялланып яшидер? Бүгенге заман кешесенә нәкъ менә болар хакында уйлану җитми дә инде.

3. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Байлык – мал күплеге түгел, хакыйкый байлык – күңел байлыгы», – дигән.

Кем соң ул күңеле бай булган кеше? Ул нинди сыйфатларга ия? Аның өстенлеге нидә? Күңеле бай кеше – ул күркәм холыкка ия булып, тәкәбберлек, саранлык, икейөзлеләнү һ.б. кебек начар гадәтләрдән ерак булган, һәрдаим шөкер кылып яшәүче. Андыйларны фани дөньяның юк-бар борчулары, берәүләрнең уңышлары хафага салмый. Алар башка кешеләрдәге бәхетне үзенеке кебек итеп кабул итә, әйләнә-тирәдәгеләр өчен куана, кирәк вакытта ярдәм итә белә. Башкалар ярдәмгә мохтаҗ булганда, моннан үзләренә файда көтмичә, ихластан булыша. Үзләре авырлыкка төшкәндә ярдәмне Аллаһыдан гына сорап, сабыр була, сабырсызлык күрсәтеп, бөтен дөньясын гаепли башламый. Бу кешеләр, чыннан да бәхетле, чөнки моңа һәркем ирешә алмый. Чынлыкта, бу бик зур сабырлык, тырышлык таләп итә. Бу пәйгамбәрләр, изге кешеләрнең халәте. Һәм әгәр Аллаһының рәхмәте белән син әлеге сыйфатларны үзеңдә табасың, икән, син бик тә бәхетле булырга тиеш.

Югарыда бәхет төшенчәсенә кагылышлы бары тик берничә аять, хәдис кенә китерелде, ә алар бихисап. Тормышыбызны яхшы якка үзгәртергә теләсәк, боларны белү дә җитәдер. Үз бәхетебезгә үзебез киртә кормыйча, уйлана, нәтиҗәләр чыгара һәм бәхетле булырга өйрәнсәк иде.

Бәхет төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый, дидек. Килешерсез. Әмма, ничек кенә аңлатырга тырышсак та, кеше күңеле тыныч булганда гына тулаем бәхетле була ала. Ә нәрсә соң ул күңел тыныч булу? Ул – җаныңның синең кылганнарыңнан канәгать булуы, чөнки җан – ул кешенең нигезе, асылы. Җаннар без бу дөньяга җибәрелгәнче үк Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылганнар. Аларга да ризык кирәк. Җанның ризыгы – үзен яратучыга табынып, аңа шөкер итеп, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәве. Тән тәфескә ияреп хаталар кылып яшәгәндә җан моңа риза булмый, ә җан риза булмаган очракта күңел тынычлык таба алмый. Ә бәхет – күңел тынычлыгында дидек. Боларны кабул итү-итмәү һәркемнең үз эше. Әмма нәрсә генә дисәк тә, барыбызның да бәхетле буласы килә.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Агулы сабак

***Дәвамы. Башы алдагы санда***

Бу төнне Раилә йокламады диярлек. Иртә белән йокымсырап киткәч кенә, ул иренең хафалы дәшүеннән уянып, күзен ачты.

– Раилә, тор, әни әллә нишләп китте бит әле! – диде шомлы тавыш белән Рәсим.

Тәненә ут капкандай сикереп торып, Раилә тизрәк каенанасы янына ашыкты. Агарынган, хәлсез, тирләп пешкән биеме караватында авыр сулап ята иде.

– Әни, нишләдең син? Нәрсә булды сиңа? – диде Раилә хафаланып, һәм куркуыннан калтырана ук башлады.

– Инде кичә үк … үземне начар хис итә башладым… Ә менә бүген… бөтенләй начараеп киттем… Эчем ут яна… – дип сүрелгән зәгыйфь тавыш белән җавап бирде ана.

«Бетте баш – өлгермәдем…» – дигән коточкыч фикер Раиләне кара кайгыга салды. Шулай нәрсә эшләргә белмичә бермәл басып торганнан соң, Рәсим: «Болай булмас, табиб кирәк», – дип телефоннан ашыгыч ярдәмгә шалтыратты. Раилә исә: «Кыяфәтенә караганда, нәрсә беләндер агуланган бугай ул. Минем шәһәрдәге бер танышым шундый авыруларны дәвалый, тиз генә барып кайтыйм әле мин», – дип, автобус тукталышына юнәлде.

25 минутлык юл очы-кырые булмаган мәңгелек булып тоелды Раиләгә шул көнне. Аллаһының рәхмәте, үлән сатучы әби урынында иде. Аның янына йөгереп килгәч, кыз үкси-үкси әбигә олы гозерен җиткерде:

– Әниебез… Әнкәбез… Бик авыр хәлдә… Зинһар, коткарыгыз!..

– Тынычлан! Әниең авырып киттемени? – диде үлән сатучы, һәм зур игътибар белән Раиләнең күзләренә бакты.

– Үз әнием түгел – каенанам! Исегездәме, минем үтенечем буенча сез аны агулар өчен миңа үләннәр биргән идегез! Әчерттем бит шуңа аларны, тинтәк, әчерттем! Ә хәзер минем аны үтерәсем килми! Ишетәсезме? Ул яшәргә тиеш! Ул… ул… бу дөньядагы иң яхшы биеем! Мин аны үз әнием кебек бик яратам… Аллаһы хакы өчен сорыйм: миңа сез биргән агуның зарарын бетерүче үләннәр бирегезче! Коткарыгыз аны, апа! Зинһар, коткарыгыз!

Раиләнең кабаланып, өзгәләнеп бик җитди гозерен белдерүенә карамастан, әби бер дә исе китмәгәндәй күзләрен кысып елмая башлады. Елап беткән кыз: «Аһ син елан… Хәйләкәр аждаһа!» – дип уйлап куярга өлгермәде, карчык аның кулын ике учы белән кысып алды да, ягымлы, йомшак тавыш белән әйтте:

– Бер дә борчылма, кызым. Теге вакытта мин бит сиңа агу түгел, ә йөрәкне ныгытучы шифалы үләннәр бирдем. Агу исә синең башыңда иде. Холкыңны төзәтеп, олы кешегә карата сабыр, күндәм, ихтирамлы булырга өйрәнеп, син шул агуыңнан арына алдың…

Әбинең шушы сүзләреннән хәйран калып, Раилә башта нәрсә диярга дә белмәде. Бераздан гына күз яшьләре аша елмаеп, әйтте:

– Һм… Алай икән… Менә хикмәт… Әмма бүген әниебез каты чирләп, урын өстендә ятып калды бит… Аның сы нәрсә булыр тагын?

– Бер дә борчылма, – дип җавап бирде әби. – Кизүдер ул, кызым, терелер әнкәгез. Мә, балакаем, менә шушы үләннең төнәтмәсен эчертерсең, булышырга тиеш. Акчасын да алмыйм! Шунысы гына бик борчый: хәзер шактый күп гаиләләрдә, яшьләр һәм өлкәннәр арасында мин-минлек, кирелек, үзсүзлелек чире таралган. Менә монысы – чыннан да куркыныч кизү. Аннан имин булыр өчен бер-береңә елмаеп, яхшы сүз әйтеп, игелекле гамәл кылып, җаннардагы боздан, каннардагы тоздан арынырга һәм башкаларны да үзеңне яраткан кебек яратырга, хөрмәт итәргә өйрәнәсе иде! Ә сезнең гаиләдә булган хәл, кызым, ул – бик күпләр өчен гыйбрәт булырлык бер хикмәтле сабак, – диде әби, һәм киң итеп елмаеп җибәрде дә:

– «Агулы» сабак! – дип атар идем мин моны! – дип, Раиләне яратып аркасыннан каккалап алды.

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

# Гәбделкаюм бабай

Таңнар атып кояш чыккач, этием урынына калган курше Каюм бабайның хәлен белергә кердем. Дөресрәге, Гәбделкаюм. Без генә яратып аны шулай дип, Каюм бабай дип йөртәбез. Үз гомерендә бернигә дә зарланмаган бу бабай, инде хәзер картайган – тормыш аның чәчләрен матур итеп ак төскә буяп куйган. Авылыбызның иң атаклы укытучысы исеменә лаек булган кеше, инде бишенче җөен ялгызы каршылый.

Өе чиста, пөхтә. Бары пәрдәләр генә саргая башлаган, төсе иңгән.

Бар нәрсәнең үз урыны бар монда һәм алар беркайчан да тишсез җирләрдә ятмыйлар. Менә бүген дә мин соңгы тапкыр кергәннән соң берни дә үзгәрмичә, үз урыннарында кала бирәләр. Тузан да беркайчан да кунмый бугай аларга: гел ялтырап тора бар нәрсә.

Кырыс кеше иде Каюм бабай, аңа карамастан аның тәрәзә төбе авылдагы яшь хуҗабикәләрнеке кебек: гел ямь-яшел һәм гел шау-чәчәктә.

– Тьфу-тьфу гөлләр мине, мин аларны яратам, шулай гына булып калсын, соңгы араларда аларга да вакыт калмый башлады, ник дисәң, сәламәтлек тә какшап тора әле, һаман авыл пунктына уколга йөрим.

Аның бит уколлары да ничектер авырттыра, белмим, картлык микән?

– Анысы да бар инде, сезнең яшьтә буыннар да ката башлый, авырулар да күбәя.

– Әйе, тик менә балалар гына онытып бетерделәр, хәбәр-хәтерләре дә юк инде менә ничә ел…, – утырып, бик авыр итеп сулыш алды мескенкәем, сүзен дәвам итеп – шуңа да мин сине үз баламнан якынрак күрә башладым: син онытмыйсың да, гел кереп, хәлемне белеп торасың, рәхмәт сиңа, анаңа да рәхмәт…

– Ә аңа ни өчен?

– Чөнки сине ул тәрбияләде, ул үстерде. Тәрбияли белеп тәрбияләү бар кешегә дә бирелми ул. Менә син гел әниең янына да кайтасың, минем яныма да керәсең, ә минем үз балаларым, мине онытып, әллә кайларга китеп югалдылар. Әниләре үлгәч, ник бер хәбәр бирсеннәр…

Каюм бабайның җыерчык баскан битләрен юешләндереп, ярылган иреннәрен әчеттереп, күзеннән кайнар яшьләр тәгәри башладылар.

– Күптән елаган юк инде, сабый чакта әткәм усалланып кайтып нигәдер орышкач, елаган идем дә, бүтән очраклар хәтергә килми. Ә монысы, бәлки, хәтта соңгысы да булыр. Гөлләремне генә кызганам: кемнәр кулына эләгерләр дә, ничек тәрбияләнерләр?..

– Ә бәлки алар кайта алмыйлардыр: бүгенге көндә күпме эш, теләсәң дә кайтып булмый, арасы да бик якыннардан түгел бит.



– Күк белән җирнең арасы тагын да ерак, монысы «чипуха» инде аның. Хәер, үз гаепләрем аркасында булды бу хәлләр: балалар үсә торды- заманасы үзгәрә барды, ә мин аны аңлый алмадым: аларнын киенү рәвеше дә, ашамлыклары да, дусларны сайлап кына алулары да, хәтта тыңлаган җырлары, биегән көйләре дә безнекеннән башка иде. Ә мин аларны мине тәрбияләгән кебек, кырыс итеп, эштән аермыйча, хезмәт сөючә итеп тәрбияләргә тырыштым. Тик алар мине, мин аларны аңлый алмадым…

– Ярар энем, мин сине үземнең моң-зарым белән туйдырдым бугай инде, әйдә әле, утыр өстәл янына, чәйләп алыйк. Соңгы арада табигать кочагына бик чыккан булмады, аны, ачуым килмәгәе, җәе дә эссе килде, эссе генә түгел кайнар дисәм дә ялгыш булмас. Үләннәрне җыярга чыккач, алар инде шиңгән иде, шулай булгач, быел бик мактый алмыйм чәемне, ләкин курше керткән тәмле бер пирогым бар, авыз итеп кара әле әйдә, чын пешекче диярсен. Алтын кул, тфү-тфү, күз тимәсен. Үзем тәрбияләгән бала ул, минем укучым. Аларга аеруча да зур рәхмәт: авылдагылары атна саен, шәһәрдәгеләр кайтан саен керәләр, Аллага шөкер, быел аларга да авыр туры килде: иген булмады, эш булмагач, акча да юк инде. Радиодан да көз буе шушы җәй вакыйгаларын сөйләп чыктылар. Колхоз гына тарала күрмәсен…

*Дәвамы бар*

**Гәбделхәким Фәсхиев**

■ **ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**


| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

■ **ҖОМГА**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Җомга тәбриге |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

■ **ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**


| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 7:50-8:05 | Миһербанлы җаннар |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 13:25-13:40 | Миһербанлы җаннар |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълиматы |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 16:50-17:05 | Миһербанлы җаннар |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Миһербанлы җаннар |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |



## «Хозур» нәшрият йорты Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Тигез гомер итегез» китабын нәшер итте

Җаваплы адымга әзерләнгән – гаилә корырга ниятләгән һәр парга нәсыйхәт бирү мөһим. Әлеге китапта матур, тату мөселман гаиләсен төзү, аны саклауга багышланган вәгазьләр тупланган. Шулай ук катнаш никах, балага мәгънәле, шәригатебезгә муафыйк исем бирү мәсьәләләре яктыртыла. Гаилә учагында бәхет, бәрәкәт яшәсен өчен, иман кирәк, «һәр гаилә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырлык итеп яшәсен», дигән изге теләк белән, автор китапта Коръәннең иң еш укыла торган сүрә-аятьләрен китерә һәм намаз уку тәртибен өйрәтә.

**Кибет:** Казан, Тукай ур., 36.
Тел.: +7 (903) 305-45-43
**Склад:** Казан, Газовая ур., 14.
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет кибет:** huzurshop.ru/




### КАЗАН ӨЧЕН МАРТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.03.2020 | 04:31 | 05:03 | 06:33 | 12:00 | 15:21 | 17:18 | 19:00 |
| 02.03.2020 | 04:28 | 05:01 | 06:31 | 12:00 | 15:23 | 17:20 | 19:02 |
| 03.03.2020 | 04:25 | 04:58 | 06:28 | 12:00 | 15:24 | 17:22 | 19:04 |
| 04.03.2020 | 04:23 | 04:56 | 06:26 | 12:00 | 15:26 | 17:25 | 19:06 |
| 05.03.2020 | 04:20 | 04:53 | 06:23 | 12:00 | 15:28 | 17:27 | 19:08 |
| 06.03.2020 | 04:18 | 04:51 | 06:21 | 12:00 | 15:30 | 17:29 | 19:10 |
| 07.03.2020 | 04:15 | 04:48 | 06:18 | 12:00 | 15:32 | 17:31 | 19:12 |
| 08.03.2020 | 04:12 | 04:46 | 06:16 | 12:00 | 15:33 | 17:33 | 19:14 |
| 09.03.2020 | 04:10 | 04:43 | 06:13 | 12:00 | 15:35 | 17:35 | 19:17 |
| 10.03.2020 | 04:07 | 04:40 | 06:10 | 12:00 | 15:37 | 17:37 | 19:19 |
| 11.03.2020 | 04:04 | 04:38 | 06:08 | 12:00 | 15:39 | 17:39 | 19:21 |
| 12.03.2020 | 04:01 | 04:35 | 06:05 | 12:00 | 15:40 | 17:41 | 19:23 |
| 13.03.2020 | 03:58 | 04:33 | 06:03 | 12:00 | 15:42 | 17:43 | 19:25 |
| 14.03.2020 | 03:55 | 04:30 | 06:00 | 12:00 | 15:44 | 17:45 | 19:28 |
| 15.03.2020 | 03:53 | 04:28 | 05:58 | 12:00 | 15:45 | 17:47 | 19:30 |
| 16.03.2020 | 03:50 | 04:25 | 05:55 | 12:00 | 15:47 | 17:49 | 19:32 |
| 17.03.2020 | 03:47 | 04:22 | 05:52 | 12:00 | 15:49 | 17:51 | 19:34 |
| 18.03.2020 | 03:44 | 04:20 | 05:50 | 12:00 | 15:50 | 17:53 | 19:37 |
| 19.03.2020 | 03:41 | 04:17 | 05:47 | 12:00 | 15:52 | 17:55 | 19:39 |
| 20.03.2020 | 03:38 | 04:14 | 05:44 | 12:00 | 15:54 | 17:57 | 19:41 |
| 21.03.2020 | 03:34 | 04:12 | 05:42 | 12:00 | 15:55 | 17:59 | 19:44 |
| 22.03.2020 | 03:31 | 04:09 | 05:39 | 12:00 | 15:57 | 18:02 | 19:46 |
| 23.03.2020 | 03:28 | 04:07 | 05:37 | 12:00 | 15:58 | 18:04 | 19:48 |
| 24.03.2020 | 03:25 | 04:04 | 05:34 | 12:00 | 16:00 | 18:06 | 19:51 |
| 25.03.2020 | 03:22 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 16:02 | 18:08 | 19:53 |
| 26.03.2020 | 03:19 | 03:59 | 05:29 | 12:00 | 16:03 | 18:10 | 19:56 |
| 27.03.2020 | 03:15 | 03:56 | 05:26 | 12:00 | 16:05 | 18:12 | 19:58 |
| 28.03.2020 | 03:12 | 03:54 | 05:24 | 12:00 | 16:06 | 18:14 | 20:01 |
| 29.03.2020 | 03:09 | 03:51 | 05:21 | 12:00 | 16:08 | 18:16 | 20:03 |
| 30.03.2020 | 03:05 | 03:48 | 05:18 | 12:00 | 16:09 | 18:18 | 20:06 |
| 31.03.2020 | 03:02 | 03:46 | 05:16 | 12:00 | 16:11 | 18:20 | 20:08 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Февраль саны, №2 (295)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2746
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25 нче февральдә таратыла.
График буенча бу санга 21 нче февраль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.